بسم الله الرحمن الرحيم

*Рахимле һәм мәрхәмәтле Аллаһ исеме белән!*

**Әлеге китап – Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ тормыш юлы, аның тышкы һәм әхлакый сыйфатлары хакында кыскача белешмәлек.**

**Һичшиксез, Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ дөньякүләм тарихта олуг һәм күренекле шәхес. Аллаһ Тәгалә аны барлык кешелек дөньясына рәхмәт өчен җибәргән, Китабыбыз Коръәндә дә шул хакта әйтелә:**

***«Без сине галәмнәргә рәхмәт өчен генә җибәрдек»*** **(«Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 107нче аять).**

**Ул ﷺ кешеләрне әти-әниләргә, гаилә әһелләренә карата хәерле мөнәсәбәттә булырга, әхлаклылыкка, өлкәннәргә ихтирам, кечеләргә мәрхәмәт күрсәтергә чакырды.**

**Әлбәттә, Мөхәммәд пәйгамбәр ﷺ өндәгән олуг сыйфатларны әлеге биттә генә санап бетерү мөмкин эш түгел. Шуңа күрә Пәйгамбәребезнең тормышы белән тирәнрәк танышырга теләгән кеше әлеге кыска гына китапны кулына алып, аны укып өйрәнергә ашыксын.**

www.sarhaan.com

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ МӨХӘММӘДНЕҢ КЫСКАЧА ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ АНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ



ХӘЙСӘМ ИБН МӨХӘММӘД СӘРХӘН

http://www.alsarhaan.com

БУЛӘК

САТЫР ӨЧЕН ТҮГЕЛ

# ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗ МӨХӘММӘДНЕҢ КЫСКАЧА ТОРМЫШ ЮЛЫ ҺӘМ АНЫҢ ФАЗЫЙЛӘТЛӘРЕ

**Әлеге хезмәтне Раббысының кичерүендә мохтаҗ булган зат үткәндә Мәдинәдә Пәйгамбәребез мәчете каршындагы институт укытучысы һәм**

**http://www.alsarhaan.com**

**сайты җитәкчесе**

**ХӘЙСӘМ ИБН МӨХӘММӘД СӘРХӘН**

**төзеде,**

**Аллаһ аның, аның әти-әнисенең һәм әлеге китапны нәшер итәргә ярдәм иткән барча кешеләрнең дә гөнаһларын кичерсен.**

Беренче басма

Китапка хокуклар сакланган

Бушка өләшү нияте белән китапны тәрҗемә итәргә теләүчеләр китапның авторы белән шушы е-майл аша элемтәгә керә ала:

**islamtorrent@gmail.com**

# КЕРЕШ СҮЗ

**Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһның исеме белән!**

Барча мактау-данлау Аллаh Тәгаләгә! Без Аңа шөкрана кылабыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аның ярлыкавын үтенәбез! Начарлыгыбыздан, бозык гамәлләребездән Аллаh Тәгаләдә сыену эзлибез! Аллаh туры юлга күндерсә, берәү дә адаштыра алмас, Аллаh адаштырганнарны исә берәү дә туры юлга кертмәс. Шәһәдәт бирәмен: Аллаhтан башка гыйбадәткә лаеклы hичбер иләhи зат юк, Ул Берүзе, Тиңдәшсез. Һәм шәһәдәт бирәмен: Мөхәммәд Аның колы һәм илчесе!

Аллаh Тәгалә әйтә:

**Ий мөэминнәр, Аллаhтан куркыгыз, Аның хөкемнәрен бозудан бик нык сакланыгыз һәм Коръән белән гамәл кылып, чын мөселман хәлегездә генә үлегез!** (“Гыймран” сүрәсе, 102нче аять)

**Ий кешеләр! Сезне бер ата-анадан яралтучы Аллаhка каршылык күрсәтүдән сакланыгыз, Ул Адәм гәләйhиссәләмнең үзеннән хатын яралтты һәм икесеннән күп ирләрне һәм күп хатыннарны дөньяга чәчте. Янә Аллаhка тәкъвалык кылыгыз ки үзегез, Ул – Аллаhның исеме белән бер-берегездән сорыйсыз, ягъни Аллаh ризалыгы өчен бир, сүземне тыңла, дисез, шулай булгач, Аллаhны зурлагыз һәм якын кардәшләр хакыннан сакланыгыз! Бит Аллаh сезнең барча эшләрегезне тикшереп күзәтүче** (“Хатыннар” сүрәсе, 1нче аять)**.**

**Ий мөэминнәр, Аллаhтан куркыгыз, Аллаhка гөнаhлы булудан сакланыгыз, һәм хак булган файдалы сүзләрне генә сөйләгез!** ( “Гаскәрләр” сүрәсе, 70 аять).

Һәм шуннан соң:

Үзенең пәйгамбәре турында, аның тормышы һәм кешеләр өчен кулланма булган сөннәте хакында гыйлем алырга аз гына булса да теләге булган һәр кеше өчен әлеге гади сүзләр бик мөhим. Бер галим әйтте: “Әгәр кешенең бу дөньядагы һәм киләчәк тормышындагы бәхете Пәйгамбәребезнең (Аллаhның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сөннәте белән бәйле икән, димәк, үзенә хәерлелек, котылу һәм җаны өчен бәхет теләгән һәр кеше Пәйгамбәребезнең (Аллаhның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) тормышы һәм сөннәте, аның әhәмияте турындагы гыйлемне шулкадәр дәрәҗәдә алырга бурычлы ки, әлеге гыйлеме белән ул бу хакта белмәүчеләрдән аерылып торырга һәм Пәйгамбәребезнең (Аллаhның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) артыннан иярүчеләр һәм аның тарафдарлары сафында булырга тиешле”. Әлеге мәсьәләдә кешеләр өч төркемгә бүленәләр: бераз гына белергә теләүчеләр, тирән гыйлем алырга теләүчеләр һәм бөтенләй мондый теләкләре булмаучылар. Һәм барча юмартлык Аллаh кулында – теләгән кешесенә бу гыйлемне бирә, чөнки Ул олуг юмартлык иясе. Мин дә, сез дә Пәйгамбәребезне яратучылардан һәм ул кушканнарны үтәүчеләрдән, ул тыйганнардан һәм кисәткән нәрсәләрдән тыелучылардан һәм ерагаючылардан булсак иде, дип Аллаhтан сорыйм.

Йә Аллаh, Ибраhимга һәм аның гаиләсенә рәхмәтеңне биргән кебек, Мөхәммәдкә һәм аның гаиләсенә дә рәхмәтеңне бир. Һәм Ибраhимга һәм аның гаиләсенә бәрәкәтеңне биргән кебек, Мөхәммәдкә һәм аның гаиләсенә дә бәрәкәтеңне бир. Дөреслектә, Син — Мактаулы һәм Олуг зат. Һәм галәмнәрнең Раббысы булган Аллаhка барча мактау!

# БЕРЕНЧЕ ӨЛЕШ: ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗНЕҢ ШӘХСИ СЫЙФАТЛАРЫ ҺӘМ КЕШЕЛӘР ӨЧЕН КУЛЛАНМАСЫ

# Пәйгамбәрнең шәхси сыйфатлары

**Аның нәселе**

Ул (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) – Мөхәммәд ибн Габдуллаһ ибн Габдел-Мотталиб ибн Хашим ибн Габдеманаф ибн Кусай ибн Киләб ибн Мурра ибн Ка'б ибн Луай ибн Галиб ибн Фихр ибн Мәлик ибн Нәдр ибн Кинан ибн Хузәймә ибн Мудрика ибн Ильяс ибн Мудар ибн Низар ибн Ма'ад ибн Гаднән.
Ә Гаднән – Ибраһим пәйгамбәрнең корбан итеп китерелергә тиешле улы Исмәгыйль токымыннан.
Һәм аның нәселе, гомумән, барлык кешеләр нәселләре арасыннан да иң яхшысы. Һәм римлыларның патшасы Ираклий Әбу Суфьянга әйткән сүзләрен бәян иткән хәдистә дә шулай диелә:
***“Мин синнән аның нәселе турында сорадым, һәм син миңа: “Ул затлы нәселдән”, - дип җавап кайтардың, әмма аңа кадәр килгән барлык пәйгамбәрләр дә затлы нәселдәндер”*.**

**Пәйгамбәрнең Аллаһ тарафыннан сайлап алынуы**

Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: "**Чынлыкта, Аллаһ Исмәгыйль токымыннан булган Кинан нәселен, шуннан соң Кинан нәселеннән Корәеш кабиләсен, корәешләрдән исә Хашим нәселен, ә Хашим нәселеннән мине сайлап алды**".

**АНЫҢ ИСЕМНӘРЕ**

Әлеге исемнәрнең барысы да башка кешеләрнеке кебек гадәти исемнәр генә түгел, алар Пәйгамбәребезне сыйфатлаучы исемнәр. Һәм алар аның мактаулы һәм камил сыйфатларыннан чыгып кушылган.

**Мөхәммәд**

Бу – аның иң билгеле булган исеме, шул рәвешле аерым-ачык итеп ул Тәүратта атала. Әлеге исемнең мәгънәсе бихисап мактаулы сыйфатлар иясе дигәнне белдерә.

**Әхмәд**

Әлеге исемнең мәгънәсе Аллаһ мәхлукъларының иң мактаулысы дигәнне аңлата. Һәм аның бихисап лаеклы сыйфатлары өчен аны җир вә күкләр, бу тормыш һәм Мәңгелек тормыш әһелләре мактыйлар. Бу исем белән аны Гайсә пәйгамбәр (галәйхиссәләм) атаган.

**Мутаваккил**

Әлеге исемнең мәгънәсе – тәвәккәл кылучы. Бу исем белән ул Ислам динен үтәүдә аның Аллаһка башка һичкем тәвәккәл итмәгән кебек тәвәккәл кылганы өчен аталган.

| АНЫҢ ИСЕМНӘРЕ | |
|---|---|
| **әл-мәхи** | Аның аша Аллаһ имансызлыкны бетерә. Һәм имансызлык аның аша бетерелгән кебек, моңарчы һичкем тарафыннан да бетерелмәгән. |
| **әл-ХАШИР** | Ул – аяклары астына халык җыйналачак зат. Һәм ул халыкны җыйнау өчен җибәрелгән сыман. |
| **әл-ГАКЫЙБ** | Аның артыннан бүтәнчә пәйгамбәрләр килмәячәк. Һәм ул соңгы пәйгамбәр, пәйгамбәрләрнең мөһере. |
| **әл-МУКАФФИ** | Ул – үзенә кадәр килгән пәйгамбәрләр һәм рәсүлләр юлын дәвам итүче, шуңа күрә дә Аллаһ аны аларның дәвамчысы итеп сайлаган. |
| Нәби әт-тәүбә | Аның аркылы Аллаһ җир әһелләре өчен тәүбә ишекләрен ачкан, һәм Ул аларның тәүбәләрен кабул иткән, әмма моңарчы мондый хәлнең булганы булмаган. Һәм Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) – Аллаһка тәүбә-истигъфарлар белән иң күп мөрәҗәгать итүче. |
| Нәби әл-мәлхәмә | Ул Аллаһның дошманнары белән көрәшү өчен җибәрелгән зат. Аллаһның рәсүле (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) үзенең өммәте белән бу юлда тырышлык куйган кебек бер пәйгамбәр дә үзенең өммәте белән тырышлык куймаган. Һәм мондый олуг сугышлар элек булмаган. |
| Нәби әр-рәхмәт | Ул Аллаһ тарафыннан бу җиргә рәхмәт йөзеннән җибәрелгән пәйгамбәр. Һәм Аллаһ, аны барлык җир әһелләренә җибәреп, Үзенең рәхмәтен күрсәткән. Иман әһелләренә килгәндә исә, алар Аллаһның рәхмәтен тулаем татыдылар, имансызларга килгәндә исә, алар арасыннан Китап әһелләре аның күләгәсе, кайгыртуы һәм килешүе астында яшәделәр. |
| әл-Фатих | Аның аркылы Аллаһ кешеләр өчен хак булган кулланма бирде. Аның аркылы Ул сукырларның күзләрен, чукракларның колакларын һәм йозаклы йөрәкләрне ачты. Һәм Аллаһ аның аркылы имансызлар илләрен, Җәннәт капкаларын, файдалы гыйлем һәм изге эшләр юлларын ачты. |

## АНЫҢ ИСЕМНӘРЕ

**әл-Әмин**

Ул – әлеге исем белән аталырга иң лаеклы зат. Аллаһ аңа Коръән һәм иманны ышанып тапшырды. Ул җир һәм күкләр әһелләренең ышанычына лаек. Хәтта имансыз корәешләр дә аны, әле пәйгамбәр булганчыга кадәр, ышанычка лаеклы, дип атадылар.

**әл-Бәшир**

Ул аңа буйсынучыларны әҗерләр белән сөендерүче, һәм аңа буйсынмаучыларны Аллаһның җәзасы белән кисәтүче.

**Сайийд уәләд Адәм**

Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Мин – Кыямәт көнендә Адәм балаларының хуҗасы һәм мин моны мактану өчен әйтмим".**

**әс-Сираҗ әл-Мөнир**

Ул – яндырылып яктырткан нәрсәләрдән аермалы буларак, янмыйча яктыртучы.

Ул – Габдуллаһ, ягъни башкаларга караганда аерата тырышлык белән гыйбадәт кылган Аллаһның колы.

## АНЫҢ ГОМУМИ СЫЙФАТЛАРЫ

Пәйгамбәребезне (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) иң камил рәвештә сыйфатлаучы кеше ул үзе булды, ул әйтте: **"Мин – Мөхәммәд, Аллаһның колы һәм рәсүле. Һәм мин үземне Аллаһ минем өчен билгеләгән дәрәҗәдән дә югары куюларын теләмим".**

Һәм ул (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) кешелек һәм әхлакый сыйфатлары буенча кешеләр арасыннан иң яхшысы иде. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Дөреслектә, син күркәм холыктасың".** ("әл-Каләм" сүрәсе, 4 аять). Гайшә дә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: **"Аның әхлагы Коръән иде".** Ул Коръән буенча, анда билгеләнгән чикләрне узмыйча яшәде, һәм ул үзенең шөкер итүен Коръәнгә тәңгәл килүе белән белдерде һәм Коръәнгә каршы килүчеләргә ачулы булды.

**Хәлил Аллаһ**

Ул (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Чынлыкта, Аллаһ мине, Ибраһимны сайлаган кебек, Үзенең якын дусты итеп сайлады".**

## АНЫҢ ТЫШКЫ КЫЯФӘТЕ

**Аның затлы бәдәне**

Әнәс ибн Мәлик әйтте: “Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) йөзе ак һәм якты, ә тир тамчылары энҗе бөртекләренә охшаш иде. Атлап йөргән вакытта ул уңга һәм сулга бөгелә иде һәм мин Аллаһ илчесенең уч төпләре сыман ефәк кебек йомшак учларга кагылганым булмады һәм һичкайчан аннан килгән хуш истән дә тәмлерәк мускус яки амбра исен тойганым булмады”.

## АНЫҢ ТЫШКЫ КЫЯФӘТЕ

**Аның буе**

Әл-Бара ибн Азиб әйтте: “Аллаһның илчесе (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) урта буйлы иде, җилкәләре киң, чәчләре колак яфракларына кадәр җитә иде. Бервакыт мин аны кызыл төстәге киемнән күрдем, һәм минем һичкайчан тышкы кыяфәте буенча аннан да күркәмрәк кешене очратканым юк иде”.

**Аның йөзе**

Ка'б ибн Мәлик әйтте: “Аллаһның илчесен (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сәламләгәннән соң, аның йөзе шатлыктан яктыра иде. Аллаһның илчесен (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) нәрсә дә булса шатландырган вакытта, аның йөзе яктыра һәм айның бер кисәге кебек була иде, һәм без аның шатланганын шуннан белә идек”.
Әл-Бардан: “Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) йөзе кылыч төсле идеме?” – дип сорадылар. Ул җавап бирде: “Юк, киресенчә, ул ай төсле иде”.

Аның чәчләре

Әнәс ибн Мәлик әйтте: “Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) куллары зур иде, һәм мин моннан соң аңа охшаш һичкемне күрмәдем, һәм аның чәчләре дулкынсыман булып, бик үк бөтеркә дә  һәм бөтенләй үк туры да түгел иде”.

Аның күзләре

Җәбир ибн Самура әйтте: “Аллаһ илчесенең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) авызы зур иде, аның күзләренең агында бераз кызыллык бар иде һәм үкчәләрендә аның ит аз иде”.

Аның тиренең хуш исе

Әнәс ибн Малик әйтте: “(Бервакыт), безгә көндезен кергәч, Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) йоклап алырга дип ятты һәм тирләде. (Шулвакыт аның янына) савыт тотып, минем әнием килде һәм шул савытка аның тир тамчыларын җыя башлады. Уянгач Пәйгамбәр сорады: "Йә Умм Суләйм, ни эшлисең син?" — һәм әнием җавап бирде: "Бу – синең тир тамчыларың, без аны үзебезнең хушбуйларыбызга кушабыз, чөнки ул иң күркәм ис тарата”.

Пәйгамбәрлек мөһере

Аның (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) аркасында ике калак сөяге арасында аерым-ачык булып миңгә охшаш пәйгамбәрлек мөһере күренеп торган.
Җәбир ибн Самура әйткән: “Мин аның калак сөягендә күгәрчен йомыркасы зурлыгында булган пәйгамбәрлек мөһерен күрдем, ул аның гәүдәсенә охшаш иде”.

## АНЫҢ ӘХЛАКЫЙ СЫЙФАТЛАРЫ

**Сәхәбәләр аны ни рәвешле олыладылар**

Әмр ибн әл-Гас әйтте: “Аллаһның илчесеннән дә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) ныграк сөйгән һәм аннан өстен күргән кешем булмады. Һәм мин аны шулкадәр тирән хөрмәт итә идем, хәтта аңа күтәрелеп карарга да кыймый идем. Әгәр миңа аның кыяфәтен тасвирларга кушсалар, мин моны эшли алмас идем, чөнки минем аңа текәлеп караганым да булмады хәтта”.

'Урва ибн Мәсгуд әс-Сакафи, Худайбия көнендә корәешләргә Аллаһның илчесен (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) тасвирлаганда әйтте:

“Аллаһ белән ант итәм, сәхәбәләр Мөхәммәдне шулкадәр хөрмәт итәләр иде ки, минем аның шикелле хөрмәт казанган бер генә патшаны да күргәнем булмады. Аллаһ белән ант итәм, әгәр ул төкерсә һәм аның төкереге берәр кешенең учына эләксә, бу кеше ул кулы белән йөзен һәм тәнен сыпыра иде; ул нәрсә дә булса әмер итсә, алар аның әмерен үтәргә ашыгалар иде; ул тәһарәт алса, аннан калган су өчен алар бер-берсе белән сугышырга әзер иде; әгәр ул сөйли башласа, алар тыналар иде; һәм алар аңа, аерата ихтирам күрсәтеп, туры карамыйлар да иде”.

**Аның Аллаһ белән әхлагы**

Габдуллаһ ибн әш-Шиххир сөйли иде: “Без Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын): “Син – безнең хуҗабыз!” – дидек. Моңа каршы ул: “Безнең Хуҗабыз – ул Бөек һәм мөбарәк Аллаһ”, - дип җавап бирде. Шуннан соң без әйттек: “Йә безнең арабыздан иң лаеклы һәм бөек булган зат! “Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **“Сүзләрегезне әйткәндә игътибарлы булыгыз, иблис сезне үз артыннан ияртмәсен!”**

**Аның батырлыгы**

Гали ибн Талиб әйтте: “Көрәш көчәйгән һәм ике төркем көрәшүчеләр бер-берсе белән сугышта очрашкан вакытта, без, яклау эзләп, Аллаһның илчесенә (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) якыная идек, ә ул исә дошманга безгә караганда якынрак буладыр иде”.

**Аның Аллаһтан куркуы**

Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **“Аллаһ белән ант итәм, чынлыкта, мин Аллаһтан сезгә караганда күбрәк куркам һәм Аның җәзасыннан сезгә караганда күбрәк сакланам”.**

**Аның гаиләсенә карата мөнәсәбәте иң яхшысы иде**

Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **“Сезнең арагызда иң яхшыларыгыз гаилә әһелләренә иң күркәм мөнәсәбәттә булганнарыгыз. Ә мин сезнең арагызда гаиләмә карата мөнәсәбәттә иң яхшысы”.**

**Аның оялуы**

Әбу Сәгыйд әл-Худри әйтте: “Аллаһның рәсүле (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) пәрдә артында утырган кыздан да катырак оялчанлык белән аерылып тора иде. Әгәр ул үзенең әхлагына туры килмәгән нәрсә күрсә, без моны аның йөз кыяфәтеннән аңлый идек”.

**Җиңелне сайлавы**

Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Аллаһның рәсүленә кайсы гына вакытта ике эшнең берсен сайларга тәкъдим итмәсеннәр, әгәр бу эш гөнаһ эш булмаса, ул һәрчак җиңелен сайлый иде, әгәр ул эштә гөнаһ булса, ул бу эштән башка кешеләргә караганда да ераграк торды...”

# АНЫҢ ӘХЛАКЫЙ СЫЙФАТЛАРЫ

| | |
|---|---|
| **Шәхсән үзе өчен үч алмады** | Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Аллаһның илчесе (беркайчан да) шәхсән үзе өчен үч алмады, ләкин әгәр Бөек Аллаһның тыйганнарыннан нәрсә дә булса бозылса, ул Аллаһ өчен үч алды”. |
| **Ризыктан гаеп тапмады** | Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Аллаһның рәсүле беркайчан да бер ризыкның да гаебен тапмады. Әгәр ул аны ашарга теләсә – ашады, теләмәсә – калдырды”. |
| **Бүләкне кабул итте** | Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Аллаһның рәсүле биргән бүләкне кабул итеп ала иде һәм бүләк бирүчегә дә җавап итеп нәрсә булса да бирә иде”. |
| **Сәдакадан ризыкланмады** | Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: “Чынлыкта, Мөхәммәднең гаиләсе сәдака итеп бирелгән нәрсәләрдән ризыкланмый”. |
| Юашлыгы | Укба ибн Әмир әйтте: “Бервакыт Пәйгамбәр янына бер кеше килде һәм аңа мөрәҗәгать итте. Кинәт сөйләшү вакытында дулкынланудан аның тавышы калтырап китте. Пәйгамбәр аңа әйтте: **“Тыныч бул, чөнки мин, чынлыкта, патша түгелмен, ә кипкән ит ашаган гап-гади хатынның улымын”.** |
| **Йорт әһелләренә ярдәме** | Әл-Әсвәд ибн Йәзид әйтте: “Мин Гайшәдән (Аллаһ аннан риза булсын) сорадым: “Гадәттә Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) өйдә нишли иде?” Ул әйтте: “Йорт әһелләренә хуҗалык эшләрендә ярдәм итә иде, намаз вакыты җитсә, намазга китә иде”. |
| Ул наданнарга игътибар итми иде | Әбу Хурайра сүзләреннән китерәләр, бервакыт Аллаһның рәсүле (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) үзенең сәхәбәләренә әйтте: “Аллаһның корәешләрнең хурлауларын һәм ләгънәтләрен миннән читкә юнәлтүе сезне гаҗәпләндермиме? Алар бит “музаммам”ны хурлыйлар, “музаммам”га ләгънәт укыйлар, ә мин – Мөхәммәд”. |
| Аның турылыгы | Габдуллаһ бин Мәсгуд әйтте: “Безгә дөрес, туры, ышанычлы булган Аллаһның рәсүле сөйләде...” |
| **Аның хезмәтчегә мөнәсәбәте** | Әнәс (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте:<br>– Мин Аллаһның рәсүленә ун ел хезмәт иттем, һәм ул миңа бер генә тапкыр да: “Уф!” , – димәде, мин нәрсә дә булса эшләсәм, ул миңа: “Син ник моны эшләдең?”, – дип әйтмәде, әгәр мин нәрсәне дә булса эшләмичә калдырсам, ул миңа: “Ник син моны эшләмәдең?” – димәде”. |

## АНЫҢ ӘХЛАКЫЙ СЫЙФАТЛАРЫ

**Ул сәхәбәләр арасыннан аерылып тормады, Аның киң күңелле һәм ачык йөзле булуы**

Әнәс, Аллаһ аннан риза булсын, әйтте дип хәбәр бирелә:
– Бервакыт без Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) белән мәчеттә утырганда, мәчет янына дөягә атланып ниндидер бер кеше килде. Ул үзенең дөясен мәчет янында тезләнергә мәҗбүр итте, аны тышаулады һәм: “Сезнең кайсыгыз Мөхәммәд?” – дип сорады. Бу вакытта Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) кулларына таянып кешеләр арасында утыра иде һәм без: “Әнә теге кулларына таянып ярым яткан ак йөзле кеше”, - дип җавап бирдек. Теге кеше аннан сорады: “Синме ул Ибн Габд әл-Мотталиб?” Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын): “Мин сине тыңлыйм”, - диде. Әлеге кеше: “Мин синнән җентекләп сораячакмын, шуңа күрә миңа ачуланмавыңны үтенәм”, - диде. Пәйгамбәр әйтте: “Ни турында теләсәң, шул турыда сора”. Бу кеше әйтте: “Мин синең Раббың һәм сиңа кадәр яшәгәннәрнең Раббылары исеменнән ялварып сорыйм, сине барлык кешеләргә дә Аллаһ җибәрдеме?” Пәйгамбәр әйтте: “Йә Аллаһ, әйе!” Бу кеше тагын сорады: “Аллаһ исеменнән ялварып сорыйм, безгә көн һәм төн дәвамында биш вакыт намаз укырга Аллаһ боердымы?” Пәйгамбәр җавап бирде: “Йә Аллаһ, әйе!” Бу кеше соравын дәвам итте: “Аллаһ исеменнән ялварып сорыйм, әйт миңа әлеге ай дәвамында ураза тотарга безгә Аллаһ боердымы?” Пәйгамбәр әйтте: “Йә Аллаһ, әйе!” Бу кеше янә сорау бирде: “Аллаһ исеменнән ялварып сорыйм, әйт миңа, безнең араларыбыздан бай булганнардан сәдака алырга һәм ярлыларга бүлеп бирергә сиңа Аллаһ боердымы?” Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: “Йә Аллаһ, әйе!” Шуннан соң бу кеше әйтте: “Мин, син алып килгән барлык нәрсәләргә дә иман китердем, һәм мин кабиләдәшләрем тарафыннан сиңа җибәрелдем, һәм мин – Димам бин Са`ләбә, бану са`д бин бәкр кабиләсеннәнмен... ”

Аның икмәге

Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, әйткән, дип хәбәр бирелә:
– Мөхәммәд вафат булганчыга кадәр аның гаилә әһелләре беркайчан да ике көн рәттән тамаклары туйганчы арпа икмәге ашамадылар.

Дөньяга бирелгән булмавы

Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **“Ухуд тавы кадәр алтыным булу шул очракта гына миңа сөенеч китерер иде, әгәр өч көннән аңардан бер генә динар да калмаса, бурычларымны түләү өчен калган акчалардан тыш, калганнарын Аллаһның колларына шулай, шулай һәм шулай, дип бүлеп бирергә боерыр идем!”**

**Әрләшмәгән**

Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Пәйгамбәр оятсыз сүзләр сөйләмәде һәм оятсыз гамәлләр башкармады, базарларда тавышын күтәрмәде, начарга начар итеп җавап бирмәде, мәгәр ул гафу итә һәм кичерә иде”.

Аның кулы чит хатын кулына кагылмады

Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Аллаһның рәсүленең кулы бер тапкыр да аңа чит булган хатынның кулына кагылмады”.

Гомәр бин әл-Хәттаб әйтте: “Мин Аллаһның илчесенә кердем, ул пальма яфракларыннан ясалган коры чыптада ята иде, мин аның янына утырдым. Мин утырдым, һәм ул өстендәге изарын җәеп җибәрде, ул мизгелдә аның өстендә шул изардан тыш башка кием юк иде. Аның тәнендә чыпта эзләре калганлыгын күрдем мин. Аллаһ илчесенең келәте ягына карадым һәм анда бер саг тирәсе арпа күрдем. Тагын бүлмәнең бер өлешендә бераз Гарәбстан сәрви агачының кузаклары бар иде һәм кайрыланмаган тире эленеп тора иде... Һәм Гомәр әйтте: “Минем күзләрем яшьләр белән тулды”. Ул сорады: **“Сине нәрсә мәҗбүр итте еларга, йә Хәттаб угълы?”** Мин әйттем: “Йә Аллаһның илчесе! Ничек инде миңа еламаска: бу чыпта синең тәнеңдә эз калдырган, келәтеңдә күргәнемнән тыш башка берни дә күрмим? Ә хосрой [Персия патшасы] һәм Византия императоры җимеш агачлары һәм елгалар арасында. Ә син Аллаһның илчесе һәм Аның тарафыннан сайлап алынган зат һәм синең бу келәтең?!” Моңа җавап итеп Аллаһның рәсүле әйтте: **“Йә әл-Хәттабның угълы! Безгә Мәңгелек тормыш әләгәчәк, ә аларга бары монысы гына, син шуннан канәгать түгелсеңме әллә?”** Һәм мин әйттем: “Әйе, әлбәттә, мин канәгать”.”

# Беренче имтихан

| Сорау: | Дөрес | Хаталы |
|---|---|---|
| • Кешенең бу тормыштагы һәм Мәңгелек тормыштагы бәхете Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) юлына ияргүгә бәйле. | ☐ | ☐ |
| • Бөтен рәсүлләр дә үз халыкларының затлы нәселләреннән булганнар. | ☐ | ☐ |
| • Пәйгамбәребезне (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) иң камил рәвештә сыйфатлаучы кеше үзе булды, ул әйтте: "Мин – Мөхәммәд, Аллаһның колы һәм рәсүле". | ☐ | ☐ |
| • Ефәк Аллаһның рәсүленең кулыннан йомшаграк. | ☐ | ☐ |
| • Аллаһ Тәгалә Үзенең пәйгамбәре өчен иң камил әхлакый һәм кешелек сыйфатларын җыйган һәм аңа гыйлем һәм дәрәҗә, абруй, шулай ук башка бер мәхлугына да бүләк итмәгәнчә, бу һәм Мәңгелек тормышта котылу, уңыш һәм бәхет чарасы булган нәрсәләрне бүләк иткән. | ☐ | ☐ |

• Кешеләрдән чыгышы буенча иң яхшысы: ☐ Йуныс ибн Мәтта ☐ Мөхәммәд ибн Габдуллаһ (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын).
• Аның исемнәре: ☐ Гадәти исемнәр генә түгел, ә аны сыйфатлаучы исемнәр. ☐ Гадәти кешеләрнеке кебек исем генә булып торалар. ☐ Алар аның мактаулы һәм камил сыйфатларыннан чыгып кушылган. ☐ Барысы да дөрес. ☐ Беренче һәм өченче җаваплар гына дөрес.
• "Аның әхлагы Коръән иде" сүзләре шуны аңлата: ☐ Ул үзенең шөкер итүен Коръәнгә тәңгәл килүе белән белдерде. ☐ Ул Коръәнгә каршы килүчеләргә ачулы булды. ☐ Ике җавап та дөрес.
• Хәлил Аллаһ – ул: ☐ Ибраһим пәйгамбәр. ☐ Мөхәммәд пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) . ☐ Икесе дә.
• “Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) йөзе ак һәм якты иде” сүзләре нәрсәне аңлата: ☐ Бодай төсендә. ☐ Ачык төстә. ☐ Ак төстә.
• Иң күркәм ис: ☐ Мускус исе. ☐ Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) тир исе.
• Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) ☐ Урта буйда иде. ☐ Озын буйлы иде.
• Аның пәйгамбәрлек мөһере ☐ Калак сөякләре арасында иде. ☐ Аның гәүдәсенә охшаш иде. ☐ Күгәрчен йомыркасы зурлыгында булды . ☐ Бөтен вариантлар да дөрес**.**

| Аллаһ сайлап алды: | Кинанны | Бану Хашим кавеменнән | Исмәгыйльне | Корәешләрдән |
|---|---|---|---|---|
| Кинанны ... нәселеннән | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Корәешне | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Бану Хашимны | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Үзенең пәйгамбәрен (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| **Аның чыгышы** | Аның исеме | Әтисенең исеме | Бабасының исеме | Бабасының әтисе | Бабасының әтисеннән дә югарырак буын | Иң өлкән бабасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Хашим | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Габделмотталиб | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Габдуллаһ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Мөхәммәд | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Исмәгыйль | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Ибраһим | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| Һәр исемне аның мәгънәсе белән бәйлә | Мөхәммәд | Әхмәд | Акыб | Сираж |
|---|---|---|---|---|
| Башкалардан күбрәк Раббысын мактаучы | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Янмыйча яктыртучы | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Бик күп мактауга лаеклы сыйфатларга ия | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Аннан соң башка пәйгамбәр булмаячак, чөнки ул пәйгамбәрлек мөһере | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын): | Куллары белән | Исе буенча | Гаиләсенә мөнәсәбәте белән | Әхлагы һәм сыйфатлары белән | Аллаһтан куркуы белән |
|---|---|---|---|---|---|
| Кешеләрдән иң яхшысы | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Иң йомшагы | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Күңелгә иң ятышлы | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Иң яхшысы | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Иң көчлесе | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын): | Аллаһ Тәгалә өчен | Ризыктан | Үзе өчен | Сәдаканы | Бүләкне |
|---|---|---|---|---|---|
| Үч алмады | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Үч алды | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Гаеп тапмады | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Кабул итеп алды һәм җавап итеп бирәр нәрсә бирде | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Кабул итмәде | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

## Аның киенү, туклану, эчемлек кабул итү рәвеше

### Аның яраткан төсе

Аның яраткан төсе ак иде. Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Сезнең киемнәрегез өчен иң яхшы төс – ак төс, шуңа күрә үзегез дә актан киенегез һәм вафат булган кардәшләрегезне дә ак кәфенгә төрегез".**

### Аның киеме

Ул гади кием киде. Ул кием йон да, мамык та, шулай ук җитеннән дә була иде. Ул уң яктан киенә башлый иде.

### Ул киеме белән башкалардан аерылып тормады

Кайбер сәләфләр сөйләделәр (Алар артык кыйммәт яки артык таушалган кием киеп йөрергә яратмадылар). Ибн Гомәр Аллаһ илчесенең болай дип әйткәнен тапшырды: "**Бу дөньяда масаю китереп чыгара торган кием кигән кешегә Аллаһ Кыямәт көнендә хурлыклы кием кидертәчәк һәм Җәһәннәмгә атачак**". Чөнки бу кешенең үзенең тәкәбберлеген һәм һавалыгын күрсәтәсе килде, һәм Аллаһ аны моның өчен җәзага тартты. Шулай ук Ибн Гомәр (Аллаһ аларның икесеннән дә риза булсын) сүзләреннән тапшыралар, бервакыт Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Мактанып, тәкәбберләнеп, үзе артыннан озын кием сөйрәгән кешегә Кыямәт көнендә Аллаһ хәтта карамаячак та ".**

### Ул нәрсә ашый иде

Ул булган ризыкны кире какмады һәм булмаган ризык хакында уйламады. Ул алдына куелган ризыкны ашады, ашарга теләмәгәнен, бу ризыкны тыелган, дип белдермичә, калдырды. Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: **"Аллаһның рәсүле беркайчан да бер ризыкның да гаебен тапмады. Әгәр ул аны ашарга теләсә – ашады, теләмәсә – калдырды"**. Мәсәлән, ул кәлтә итен ашамаган, чөнки ул кәлтә итен ашарга күнекмәгән булган.

### Аның туклану рәвеше

– Күбрәк ул җиргә җәелгән җәймәдән ашаган.
– Ул өч бармагы белән ашаган.
– Ашаган вакытында таянмаган.
– Ашый башлаганда ул "бисмиЛләһ" ("Аллаһның исеме белән") дигән, ризыкланып туйгач, "әлхәмдүЛлиләһ" дип, Аллаһны мактаган.
– Ризыкланып туктагач, бармакларын ялаган.

### Аның эчү рәвеше

– Гадәттә ул утырып эчкән һәм басып эчүне тыйган (әгәр утырып эчәргә комачау итүче катгый сәбәпләр булмаса).
– Эчкән вакытта ул савытны уң ягында торучыга биргән, хәтта аның сул ягында өлкән кеше булса да.

## Аның никахы һәм хатыннары белән мөнәсәбәте

– Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: "Минем күңелемә бу дөньялыктан хатын-кызларга, ислемайларга мәхәббәт салынган һәм намаз минем өчен ял итеп яратылган".
– Ул үзенең хатынары арасында үзенең төннәрен, алар янында булган вакытны һәм аларга чыгымнарны бүлгән.
– Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйткән: "Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сәфәргә барырга теләсә, хатынары арасында жирәбә сала иде. Кемнең угы чыкса, шул хатын аның белән сәфәргә бара иде. Юлда булганда калган төннәрен өйдә калган хатыннарына кире кайтармады".
– Аның үзенең хатыннарына мөнәсәбәте иң яхшы мөнәсәбәтнең һәм әхлакның чагылышы.
– Ул Гайшәгә (Аллаһ аннан риза булсын), аның белән уйнасыннар өчен, ансарлар кызларын җибәрә торган булган. Һәм аңа нинди дә булса уен ошаса һәм ул уенда бернинди начарлык та булмаса, аннан тыймаган.
– Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте, дип җиткерәләр: "Аллаһның рәсүле минем хәйд булган вакытта еш кына минем тезләремә башын куя иде һәм Коръән укый башлый иде".
– Хәйд вакыты булганда, ул Гайшәгә изар кияргә кушкан һәм шуннан соң ул аның белән ләззәтләнгән.
– Ураза тоткан вакытында ул аны үбә торган булган.
– Аның игелеге һәм күркәм әхлагы чагылышы шунда иде ки, ул Гайшәгә уйнарга рөхсәт итә иде, аның белән ике тапкыр, озын сәфәрдә булганда, куышып йөгергән, бервакыт йортларыннан чыкканда этешеп тә уйнаган.
– Әгәр ул ерак сәфәрдән төнлә кайтса, хатыннарының ишекләрен шакымаган, башкаларны да моны эшләүдән тыйган.

## Аның йоклау һәм уяну рәвеше

– Аллаһның рәсүле (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) йокларга яткан вакытта**: "Синең исемең белән, йә Аллаһ, мин терелӛм һәм үләм"**, - дип дога кылган. Шулай ук һәр төнне ул учларын кушып төкергән, шуннан соң укый торган булган: **"Әйт: "Ул, Аллаһ – бер",** һәм "Әйт: **"Таңның раббысына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәм",** һәм "Әйт: **"Кешеләрнең Раббысына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәм"** , һәм шуннан соң учлары белән, буе җиткәнчә, тән әгъзаларын башыннан, йөзеннән алып гәүдәсенең алгы өлешен һәм шуннан соң башка өлешләрен сыпырган. Ул моны шул рәвешле өч тапкыр эшли торган булган. Шулай ук ул йокларга ятарга теләсә, үзенең уң кулын уң бит астына сала торган булган һәм өч тапкыр әйткән: **"Йә Аллаһ, Үзеңнең колларыңны терелткән көндә мине Үзеңнең җәзаңнан сакла".** Йокысыннан уянган вакытта, ул болай дип әйтә торган булган: "**Безне үлемнән соң терелткән Аллаһка барча мактаулар булсын, һәм бары Аңа гына кайтачакбыз**" һәм шуннан соң ул тешләрен мисвак белән чистарткан.
– Гадәттә ул төннең беренче өлешендә йоклаган, ә икенче өлешендә төнге намазлар укыган. Кайвакыт ул, мөселманнарның эшләре белән шөгыльләнгән вакытта төннең беренче өлешендә йокламаган.
– Аның күзләре йоклый иде, әмма йөрәге бер дә йокламады.
– Ул йоклаган вакытта, үзе уянмыйча, аны беркем дә уятмаган.
– Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) йокысы бик озак та, бик кыска да булмаган, уртача булган, шундый йокы иң файдалы йокыдыр.

| Кешеләр белән мөнәсәбәте | |
|---|---|
| | – Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) шаярткан вакытлары була иде, әмма шаярганда да ул һәрвакыт дөресен сөйләде.<br>– Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сорауга икеләнеп җавап биргән вакытлары була иде, ләкин хәтта мондый очракларда да ул дөресен сөйли иде.<br>– Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) киңәш бирә иде, үзе дә киңәш сорый иде.<br>– Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) авыру кешенең хәлен белә иде, җеназада катнаша иде, чакыруларга җавап бирә иде, тол калган хатынның, зәгыйфь, мохтаҗ кешенең эше белән йөри иде.<br>– Үзенә карата шагыйрьләрнең мактавын ишетсә, Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) аларга берәр төрле бүләк биреп рәхмәтен белдерә иде. Бу мактау ул лаек булган мактауның бары бер өлеше генә. Башка кешеләрне мактауга килгәндә исә, аларның күпчелеге ялган.<br>– Ул үз куллары белән үзенең аяк киемен рәтләгән, өс киемен һәм чиләген ямаган. Ул сарыкны сауган, киемнәрен карап торган, үзенең йорт әһелләренә һәм үзенә хезмәт күрсәткән, мәчет төзегәндә башкалар белән беррәттән балчык кирпечләр ташыган.<br>– Кайвакыт ул, ач булганлыктан, эченә таш бәйләп йөргән, кайвакыт исә тамагы туйганчы ашаган.<br>– Ул кунакларны кабул иткән һәм үзе дә кунак булган.<br>– Аның башының уртасына, аяк табанының арткы ягына, муен тирәсеннән аркасының ике ягына һәм муен төбенә кан чыгару ясаганнар.<br>– Авырган вакытында ул дәвалана иде. Һәм үзен кызган тимер бастырып дәвалый иде, әмма кемнәндер моны үзенә эшләвен сорамый иде. Ул үзен-үзе өшкерә иде, ләкин кемнәндер моны үзенә эшләвен сорамый иде. Һәм ул авыруны аңа зыян сала торган әйберләрдән саклый иде.<br>– Ул кешеләр белән мөгамәләдә иң яхшысы булды. Әгәр ул кемнәндер нәрсә дә булса алып торса, алып торганнан да яхшырак рәвештә кайтара иде. |
| Атлап йөрү рәвеше | Аның атлап йөреше иң җиңеле иде, әмма шул ук вакытта ул матур һәм тавышсыз йөри иде.<br>Ул үзе белән бергә баручыларга караганда кызурак атлый, шуңа күрә калганнарга аны куып җитү өчен тырышырга кирәк иде.<br>Ул ялан аяк та, сандалилар белән дә йөри иде.<br>Кайвакыт аның белән бергә баручылар алданрак барып, ул арттан бара торган иде.<br>Кешеләр белән барганда, ул аерым да, шулай ук төркемдә дә барырга мөмкин иде. |
| Аллаһны зикер итүе | Ул (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) Аллаһны зикер итүдә кешеләрдән иң камиле иде. Алай гына да түгел, аның бөтен сөйләме Аллаһны зикер итү иде һәм ул бары тик Аллаһ сөйгән нәрсәләрне генә сөйли иде. Ул йокыдан уянганда, намаз укый башлаганда, өйдән чыкканда, мәчеткә кергәндә, иртән һәм икендедән соңгы вакытта, кием кигәндә, йортка кергәндә, аннан чыкканда, бәдрәфкә кергәндә, тәһарәт алыр алдыннан һәм аннан соң, азан ишеткәч, яңа ай күргәч, ашый башлаганчы һәм ашап бетергәч, төчкергән вакытта Аллаһны зикер итә иде. |

| | | |
|---|---|---|
| Кешенең табигый асылына һәм шуңа якын нәрсәләргә кагылышлы сөннәтләр | **Әлеге сөннәтләрнең исемлеге** | Аллаһның рәсүле әйтте:<br>– Ун нәрсә фитрадан (табигый): мыекларны кыскарту, сакал үстерү, теш чистарткыч куллану, борынны су белән юу, бармакларның буыннарын юу, култык астындагы йоннарны йолку, касыктагы йоннарны кыру һәм юыну өчен су куллану. Хәдисне тапшырган кеше унынчы нәрсә хакында оныткан. |
| | Уң якка өстенлек бирүе | Ул аяк киемен уң аяктан кия, уң яктан чәч тарый иде, аңа тәһәрәт алганда уң яктан башлау, уң кул белән нәрсә дә булса бирү яки алу ошый иде. Ул уң кулы белән ашый, эчә, тәһәрәт ала иде, ә сул кулын йомышын йомышлаганда, нинди дә булса пычрактан чистарынганда куллана иде. |
| | Чәчен кыркуы | Әгәр аңа чәчен кыркырга кирәк булса, ул яки башындагы бөтен чәчен дә кырыккан, яки бөтенләй алмаган. |
| | Мисвәк | Ул мисвәк (теш чистарткыч) кулланырга ярата иде һәм аны уразасыз килеш кенә түгел, хәтта уразалы килеш тә куллана иде. Шулай ук йокыдан уянгач та, тәһәрәт алганда да, намаз алдыннан да, өйгә керер алдыннан да тешләрен мисвәк белән чистарта иде, моның өчен ул арак тамырыннан ясалган таякчыклар куллана иде. |
| | **Исле-майлар** | Ул үзенә бик күп ислемайлар сибә иде һәм ислемайлар яратты. |
| | **Мыек һәм сакал** | Ул әйтте: **“Мөшрикләрдән аерылып торыгыз: сакалларыгызны җибәрегез, мыекларыгызны кыскартыгыз”.** |
| | Мыек һәм тырнаклар-ны кису | Әнәс (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Пәйгамбәр безнең өчен кырык көнгә бер мәртәбә булса да мыекларны һәм тырнакларны кисәргә кирәклекне билгеләде”. |
| Аның сөйләшү рәвеше | Аның сөйләме | – Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: “Аллаһның рәсүле сез сөйләгән кебек кызу һәм аңлаешсыз итеп түгел, ә, киресенчә, аерымачык һәм төгәл итеп сөйли иде, һәм аның белән бергә утыручылар ул әйткәнне истә калдыралар иде”.<br>– Кайвакыт ул, аны аңласыннар өчен, әйтәсе сүзен өч тапкыр кабатлый иде һәм сәламләгән вакытта да өч тапкыр сәламли иде.<br>– Зарурлык булмаса, ул сөйләми иде, сөйләгән очракта да, кыска һәм эчтәлекле итеп сөйләде.<br>– Ул һичкайчан кычкырмады һәм бервакытта да әдәпсез, оятсыз сүзләр сөйләмәде һәм шундый гамәлләр кылмады. |

| | | |
|---|---|---|
| **Аның сөйләшү, көлү, елау һәм кешеләргә вәгазь белән мөрәҗәгать итү рәвеше** | Аның көлүе | Аның көлүе дә тыйнак булды, ул елмайган сыман көлә иде, ә азау тешләре күренүе исә аның көчле көлүе хакында сөйли иде. |
| | Аның елавы | – Ул үксеп яки кычкырып еламады, бары тик аның күзләреннән яшь тамчылары гына тәгәри иде, һәм аның елау вакытындагы сулышы тагын да тирән була иде.<br>– Кайвакыт ул вафат булган кешене кызганып, кайчакларда өммәте өчен куркып һәм кызганып, кайвакыт Аллаһтан куркып, кай чакларда Коръән тыңлап елый иде. |
| | **Аның вәгазьләре** | – Ул вәгазьләрен җиргә басып та, мөнбәрдән дә, ата һәм ана дөя өстеннән дә сөйли иде.<br>– Җәбир (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: «Аллаһның рәсүле кешеләргә вәгазь белән мөрәҗәгать иткән вакытында, аның күзләре кызара, тавышы катылана, ул үзе, башкаларны явыз дошман явыннан кисәткән кеше сыман ачулы була иде”.<br>– Һәр вәгазенең башында ул Аллаһны мактый иде.<br>– Ул зарурлык булганда һәм кешеләр өчен файдасы булган һәр очракта да вәгазь сөйли иде. |

# Икенче имтихан

| Сорау | Дөрес | Хаталы |
|---|---|---|
| Ул көлмәген уң яктан кия башлый иде. | ☐ | ☐ |
| Башлыча ул җиргә җәелгән җәймәдән ашый иде. | ☐ | ☐ |
| Әгәр ул ерак сәфәрдән төнлә кайтса, хатыннарының ишекләрен шакымаган, башкаларны да моны эшләүдән тыйган. | ☐ | ☐ |
| Кайвакыт ул, ач булганлыктан, эченә таш бәйләп йөргән, кайвакыт исә тамагы туйганчы ашаган. | ☐ | ☐ |
| Авырган вакытында ул дәвалана иде. Һәм үзен кызган тимер бастырып дәвалый иде, әмма кемнәндер моны үзенә эшләвен сорамый иде. Ул үзен-үзе өшкерә иде, ләкин кемнәндер моны үзенә эшләвен сорамый иде. | ☐ | ☐ |
| Төрле коткыларга бирелүче кешеләр кыла торган гамәлләрне кылмый иде, мәсәлән, кече йомышын башкарганнан соң, ул үзенең җенес әгъзасыннан бәвелне селкеп чыгармый, йөткерми һәм сикергәләми иде, бау тартмый, баскычтан менми, бәвел чыгу каналына мамык тыкмый, ул урынга гел су сибеп тормый, һәрдаим күздән кичереп тормый һәм башка шундый гамәлләр эшләми иде. | ☐ | ☐ |
| Ул ширекнең һәм рөхсәт ителгәнне тыюның капма-каршысы булган Тәүхид һәм шәфкатьлелек белән килде. | ☐ | ☐ |
| Аның җиде баласы – дүрт улы һәм өч кызы бар иде. | ☐ | ☐ |
| Аның барлык балалары да Хәдичәдән булып, калган хатыннарыннан балалары юк иде. | ☐ | ☐ |
| Аның барлык балалары да үзе исән вакытында вафат булдылар. | ☐ | ☐ |
| Ул вафат булган чагында аның тугыз хатыны – Гайшә, Хафсә, Зәйнәб бин Джәхш, Умм Сәләмә, Сафийя, Умм Хәбибә, Мәймунә, Сәүдә һәм Җөвәйрия – бар иде, дигән фикер каршылык тудырмый. | ☐ | ☐ |
| Аллаһ Тәгалә Хәдичәгә һәм бары тик аңа гына Җәбраил фәрештә аркылы сәлам тапшырды, һәм тагын башка хатыннарының берәрсенә сәлам җибәрелүе билгеле түгел. | ☐ | ☐ |

Аның яраткан төсе: ☐ Ак. ☐ Кара. ☐ Башка бүтән төсләр.
Аның киеме: ☐ Йоннан. ☐ Мамыктан яки җитеннән булган. ☐ Нинди киеме булса, шундыйны кигән. ☐ Бары тик беренче һәм икенче җаваплар гына дөрес.
Аның киеме: ☐ Кыйммәтле. ☐ Талымсызлыгы аркасында иң арзанлы. ☐ Уртача булган.

Ул "бисмиЛләһ" ("Аллаһның исеме белән") дигән сүзне Аллаһны мактап: ☐ Ашый башлаганчы. ☐ Ашап бетергәч. ☐ Ашый башлаганда һәм ашап бетергәч әйткән.
Суны ул: ☐ Утырып эчкән. ☐ Басып эчкән. ☐ Ике вариант та дөрес.
Пәйгамбәр әйткән: "Минем күңелемә бу дөньялыктан ... мәхәббәт салынган".
☐ Хатын-кызларга. ☐ Ислемайларга. ☐ Ике вариант та дөрес.
Ул әйтте: "һәм ... минем өчен ял итеп яратылган". ☐ Җәннәт. ☐ Намаз. ☐ Ике вариант та дөрес.
Аның үзенең хатыннарына мөнәсәбәте: ☐ Иң яхшы мөнәсәбәтнең чагылышы.
☐ Әхлакның чагылышы. ☐ Ике вариант та дөрес.
Әнәс (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: "Пәйгамбәр безнең өчен ... бер мәртәбә булса да мыекларны һәм тырнакларны кисәргә кирәклекне билгеләде":
☐ Утыз көнгә. ☐ Кырык көнгә. ☐ Илле көнгә.
Әгәр аңа чәчен кыркырга кирәк булса, ул: ☐ Чәченең бер өлешен кырган, бер өлешен калдырган. ☐ Яки башындагы бөтен чәчен дә кырыккан, яки бөтенләй кырыкмаган.
Ул мисвәк кулланырга ярата иде һәм аны: ☐ хәтта уразалы килеш тә куллана иде.

☐ уразасыз килеш куллана иде. ☐ Ике вариант та дөрес.

Аның көлүе: ☐ Һәрвакыт елмайган сыман гына булды. ☐ Күп очракта елмайган сыман булды.

Ул Аллаһ тарафыннан рәсүл итеп: ☐ Барлык кешеләргә җибәрелде. ☐ Барлык кешеләргә һәм җеннәргә җибәрелде.

Аның иң яхшы кызларыннан: ☐ Барысы да ☐ Фатыйма ☐ Зәйнәб.

Аңа бары тик бер хатыны белән генә ятакта ятканда Аллаһтан вәхий иңә иде һәм ул хатыны: ☐ Хафсә ☐ Умм Сәләмә ☐ Гайшә.

| Пәйгамбәр | җеназада | чакыруга | тол калган хатынның, зәгыйфь, мохтаҗ кешенең эше белән | Авыру кешенең |
|---|---|---|---|---|
| хәлен белә | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| катнаша | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| җавап бирә | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| йөри | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| **Анның эшләреннән:** | Үзенең сарыгын | Мәчет төзелеш өчен кирпечләр | Үзенең киемен | Үзенең аяк киемен | Үзен һәм үз гаиләсен |
|---|---|---|---|---|---|
| төзәтте | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| ямады | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| сауды | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| хезмәт күрсәтте | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| ташыды | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| **Кешенең табигый асылына кагылышлы сөннәтләр:** | тырнакларны | Култык астын | Касык өлешен | сакалны | мыекны |
|---|---|---|---|---|---|
| кыскарту | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| калдыру | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| кисү | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| йолку | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| **Анның ашау рәвеше** | Үзендә булмаган ризык хакында | Ул ризыкны тыелган, дип белдермичә, калдырды | Ашый иде | Үзендә булган ризыкны |
|---|---|---|---|---|
| Кире какмады | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Уйламады | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Яхшы ризык бирсәләр | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Әгәр ризык аңа ошамаса | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| Ул болай эшли иде: | Ашап бетергәч | Ризыкны ашады | Бер бармак белән ашый | Биш бармак белән ашый | Өч бармак белән ашый |
|---|---|---|---|---|---|
| Бармаклары белән ашады | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Бармакларын ялады | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Булдыра алганча хөрмәт белән | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Тәкәббер кеше | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Комсыз кеше | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

# Аны аерып торучы сыйфатлар

**АНЫ АЕРЫП ТОРУЧЫ СЫЙФАТЛАР**

| | |
|---|---|
| **Ул Тәүхид һәм шәфкатьле-лек белән җибәрелде** | Бер галим әйтте: “Анда Тәүхид белән шәфкатьлелек сыйфаты берләшкән иде, бу исә ширекнең һәм рөхсәт ителгәнне тыюның капма-каршысы”. |
| **Ул кешеләргә дә, җеннәргә дә җибәрелде** | Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: “**Башка пәйгамбәрләр бары үз халкына гына җибәрелде, ә мин бөтен халыкларга да җибәрелдем"**. |
| Аның Китабы һәм чакыруы | Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Әлиф ләм ра. Ошбу китапны сиңа кешеләрне батыл ялган дин караңгылыгыннан чыгарып, хак дин яктылыгына, Раббыларының теләге белән галиб вә мактаулы булган Аллаһ юлына кертү өчен дип иңдердек"** (“Ибраһим” сүрәсе, 1нче аять). |
| **Аның могҗизал ары** | Аңа бүләк ителгән иң олуг могҗиза – ул Коръән. Һәм аңа кадәр килгән пәйгамбәрләргә нинди генә могҗиза бирелмәсен, ул могҗизаларның бер өлеше пәйгамбәребезгә дә бүләк ителгән иде. |
| Аңа карата булган мәхәббәт Иманның билгесе булып тора | Ул (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Мине балагызга, әтиегезгә яки барлык башка кешеләргә караганда да катырак яратмыйча торып, берегез дә иман китермәс".** |
| Аны күрәлмау-чылар | Аны күралмаган кеше имансызга әйләнә. Аллаһ Тәгалә әйтә: **“Чынлыкта, сине күралмаучы кеше үзе – нәселе бетүчедер” .** (“Әл-Кәүсәр” сүрәсе, 3нче аять). |
| Хәлил | Ул (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Чынлыкта, Аллаһ мине, Ибраһимны сайлаган кебек, Үзенең якын дусты итеп сайлады".** |
| Ныклы тәвәккәл-леккә ия кешеләрнең берсе | Аллаһ Тәгалә әйтте: **“Без пәйгамбәрләрдән өммәтләрегезгә шәригать хөкемнәрен ирештерегез, аларны хак юлга Ислам диненә өндәгез дип килешү алдык, шулай ук синнән, Нух, Ибраһим, Муса вә Мәрьям угълы Гыйсадан килешү алдык" (“Әл-Әхзәб” сүрәсе, 7нче аять).** |
| Аның гыйлеме | Ул әйтте: **"Миңа килгәндә исә, мин, чынлыкта, Аллаһ турында сезгә караганда күбрәк беләм". Аллаһ Тәгалә әйтә: “Әйт (Пәйгамбәр): "Мин сезгә Аллаһ хәзинәләре минем кулымда, яшерен нәрсәләрне беләмен һәм мин фәрештәмен, дип әйтмимен", – дип"** (“Әл-Әнгам” сүрәсе, 50нче аять). |

# АНЫ АЕРЫП ТОРУЧЫ СЫЙФАТЛАР

## Аңа буйсынган һәм аңа карышкан кешенең халәте

Аллаһ Тәгалә әйтте:
**"Әйт (йә Пәйгамбәр): “Әгәр Аллаһны сөяр булсагыз, миңа иярегез, миңа иярсәгез, Аллаһ сезне сөяр һәм гөнаһларыгызны гафу итәр"** (“Әл-Гыйммран” сүрәсе, 31нче аять).
Һәм Ул шулай ук әйтте: **"Ий мөэминнәр! Дошманнарыгыздан курыкмагыз, зәгыйфьләнмәгез, Ухуд сугышында зарар күргәнегез өчен хәсрәтләнмәгез, әгәр Аллаһ сүзенә ышанучылардан булсагыз, киләчәктә, әлбәттә, сез өстен булачаксыз!"**(“Әл-Гыймран” сүрәсе, 139нчы аять).
Һәм Аллаһның рәсүле әйтте: **“Минем өммәтемнең бөтен әгъзасы да, ваз кичкәннәрдән тыш, җәннәткә эләгәчәк”.** (Кешеләр) сорады: **“Йә Аллаһның рәсүле, кем ваз кичәчәк?” Ул әйтте: “Кем миңа буйсына, ул җәннәткә керәчәк, ә миңа буйсынмаган кешеләр ваз кичәчәкләр”.**
Һәм Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: "... минем әмерләремә карышкан кешегә хурлык һәм түбәнлек”.

## Аның өммәте

Аллаһ Тәгалә әйтте:
**"Йә сез Мөхәммәд өммәте, дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, Аллаһка хак ышану белән ышандыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыйдыгыз”**
(“Әл-Гыймран” сүрәсе, 110нчы аять).
Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Кулларында Мөхәммәднең җаны булган Зат белән ант итәм, (ягъни Аллаһ белән) чынлыкта, мин ышанам, сез Җәннәткә эләгүчеләрнең яртысын тәшкил итәчәксез".**

## Аның шәһәре

Аның шәһәре – Мәккә. Аллаһ Тәгалә әйтте: **"Дөреслектә, кешеләргә гыйбадәт кылу өчен салынган йортның әүвәле Мәккәдәге Кәгъбәтулладыр. Мәккә шәһәре кешеләр өчен мөбарәк, ә Кәгъбәтулла барча галәмнәр өчен һидәят билгесе. Ул Кәгъбәтуллада билгеле галәмәтләр бар, шулардан берсе Ибраһим галәйһиссәләмнең ташка баткан аяк эзләредер. Анда кергән кеше гаепле булса да, анда чагында хөкем ителүдән иминдер. Көче җиткән кешеләргә Аллаһка гыйбадәт өчен хаҗ кылу фарыз. Берәү хаҗның фарызлыгын инкяр итсә, көче җитеп тә хаҗ кылмаса, зарары үзенә. Аллаһ бөтен галәмнәр мәхлугыннан мөстәгънидер, һичберсенең гамәленә мохтаҗ түгел, карышкан кешеләрне газап кылыр"** (“Әл-Гыймран” сүрәсе, 96-97нче аятьләр).
Мәккә шәһәре гөнаһлар кылу өчен тыелган шәһәр. Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Чынлыкта, Аллаһ бу шәһәрне инде күкләрне һәм җирне халык кылган көнне үк гөнаһ кылу өчен тыелган шәһәр итте, һәм Мәккә Аллаһ аны шундый итеп кылган өчен тыелган шәһәр”.** Һәм Мәккә Кыямәт көненәчә мөселманнар шәһәре булып калачак, чөнки Аллаһның рәсүле әйтте: “**Мәккә азат ителгәннән соң хиҗрәт юк**”.

## АНЫ АЕРЫП ТОРУЧЫ СЫЙФАТЛАР

### Аның намаз укыган вакыттагы кыйбласы

Аның намаз укыган вакыттагы кыйбласы – Кәгъбә. Кәгъбә кыйбла булганчыга кадәр, ул намазны Иерусалим ягына карап укый иде.
Аллаһ Тәгалә әйтте:
**“Әлбәттә, ий Мөхәммәд, йөзеңне күккә күтәреп торуыңны күрәбез. Әлбәттә, сине үзең теләгән Кәгъбәтуллага юнәлдерербез. Менә хәзер йөзеңне юнәлдер Хәрам мәчете эчендәге Кәгъбәтуллага! Кайда гына булсагыз да, йөзләрегезне Кәгъбәтуллага юнәлдерегез!”**
(“Әл-Бәкара” сүрәсе, 144нче аять).
Һәм Мәккәдәге әл-Хәрам мәчете җир йөзендә торгызылган беренче мәчет. Әбу Зарр (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: "Мин Аллаһның рәсүленнән (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) җир йөзендәге беренче мәчет нинди мәчет, дип сорадым. Ул әйтте: **“Әл-Хәрам мәчете”.**
Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) шулай ук әйткән: **"Кем дә кем әшәке сүзләр сөйләмичә, гөнаһ һәм килешмәгән гамәлләр кылмыйча ул Йортка барса, өенә анадан туган вакытындагыча гөнаһсыз һәм чиста килеш әйләнеп кайтыр”.**

Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Әл-Хәрам мәчетендә укылган бер намаз йөз мең намазга, минем мәчетемдә укылган бер намаз мең намазга, Иерусалим мәчетендәге бер намаз исә биш йөз намазга тиң”.**
Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Өч мәчеттән: Мәккәдәге әл-Хәрам, Мәдинәдәге минем мәчетем, Иерусалимдагы әл-Аксадан гайре намаз уку өчен башка мәчетләргә махсус барырга кирәкми”.**
Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) әйтте: **"Кече яки олы йомышыгызны үтәргә теләсәгез, аны кыйблага карап та, кыйблага аркагызны куеп та үтәмәгез, ә көнчыгыш яки көнбатыш юнәлешенә таба карап басыгыз”.**

# АНЫҢ ТУГАННАРЫ һӘМ ХАТЫННАРЫ

**Аның җиде баласы бар иде: өч угылы һәм дүрт кызы**

(1) әл-Касыйм, Пәйгамбәрнең куньясы аның исеме буенча булды

(2) Зәйнәб (Аллаh аннан риза булсын).

(3) Рукайя (Аллаh аннан риза булсын).

(4) Умм Көлсем (Аллаh аннан риза булсын).

(5) Фатыйма (Аллаh аннан риза булсын).

(6) Габдуллаh, аны әт-Таййиб һәм әт-Таһир дип йөртәләр иде.

(7) Ибраһим, бу улы кол хатын Мәрьямнән иде. Пәйгамбәрнең (Аллаhның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) башка барлык балалары да Хәдичәдән булып, башка хатыннарыннан балалары юк иде.

Аның барлык балалары да, Фатыймадан калганнары, үзе исән чагында ук вафат булганнар иде. Фатыйма исә атасы вафатыннан соң алты айдан бакыйлыкка күчә. Фатыйманың сабырлыгы һәм әҗер-савапларга өмете өчен Аллаh аны шундый дәрәҗәләргә күтәрде ки, ул хатын-кызлар арасында да, Пәйгамбәрнең кызлары арасында да иң яхшы хатыннардан санала. Барлык кызлары да аның пәйгамбәрлек миссиясенә кадәр яшәделәр, аларның барысы да Ислам динен кабул иттеләр һәм аның белән бергә Мәдинәгә хиҗрәт кылдылар.

**Аның унбер агасы**

(1) Хәмзә, шаhитларның хуҗасы (Аллаh аннан разый булсын)

(2) әл-Габбас (Аллаh аннан разый булсын)

(3) Әбу Талиб, аның исеме Габде Мәнәф.

(4) Әбу Ләхәб, аның исеме Габдел-Гуззә.

(5) әз-Зөбәйр.

(6) Габдел-Кагъбә.

(7) әл-Мукаввим.

(8) Дирар

(9) Кусам.

(10) әл-Мугыйра, аны Хәҗел дип атыйлар иде.

(11) әл-Гайдак, аның исеме Мусгәб.

Аның агаларыннан бары тик Хәмзә һәм әл-Габбас кына (Аллаh аларның икесеннән дә риза булсын) Ислам динен кабул иттеләр.

**Аның алты апасы**

| | | | |
|---|---|---|---|
| (1) Сафийя, ул әз-Зөбәйр ибн әл-Гаввамның әнисе. | | (2) Умм Хәким әл-Бәйда. | |
| (3) Гатикә . | (4) Бәрра. | (5) Әрва. | (6) Умәймә. |

Аның унбер хатыны (исемнәре истә калдыру өчен җиңеләйтелгән вариантта бирелә),

| | |
|---|---|
| حجز | (Х) – Хафсә бинт Гомәр ибн әл-Хаттаб.<br>(Җ) – Җөвәйрия бинт Харис.<br>(З) – Зәйнәб бинт Джәхш + Зәйнәб бинт Хузәймә. |
| صخر | (Сад) – Сафийя бинт Хуяй ибн Әхтәб.<br>(Х) – Хәдичә бинт Хувәйлид.<br>(Р) – Умм Хәбибә Рамлә бинт Әбу Суфьян. |
| سمعه | (Син) – Сәүдә бинт Зәм’а.<br>(М) – Мәймүнә бинт Харис.<br>(Гайн) – Гайшә бинт Әбу Бәкр.<br>(Х) – Умм Сәләмә Хинд бинт Әбу Умәйя. |

**Хәдичә (Аллаһ аннан риза булсын)**

Пәйгамбәрнең беренче хатыны – Хәдичә бинт Хувәйлид әл-Курашийя әл-Әсәдийя (Аллаһ аннан риза булсын). Ул аңа пәйгамбәрлек иңгәнче өйләнгән иде һәм аңа ул вакытта кырык яшь булды. Хәдичә исән вакытта ул башка хатыннарга өйләнмәде. Ибраһим дигән улыннан кала, аның барлык балалары да Хәдичәдән. Пәйгамбәрлек иңгәч, ул аңа ярдәм итте һәм аның белән бергә аеруча тырышлык куя иде, гамәлләре һәм малы белән аңар ярдәм итә иде. Һәм Аллаһ Тәгалә Хәдичәгә Җәбраил фәрештә аркылы сәлам тапшырды, һәм башка хатын-кызга Аллаһ тарафыннан мондый хөрмәт күрсәтелүе билгеле түгел. Ул Мәдинәгә хиҗрәт кылырга өч ел кала вафат була.

**Сәүдә (Аллаһ аннан риза булсын)**

Беренче хатынының вафатыннан соң берничә көннән Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) Сәүдә бинт Зәм’а әл-Курашийяга (Аллаһ аннан риза булсын) өйләнә. Ул аның үз көннәрен Гайшәгә (Аллаһ аннан риза булсын) бүләк иткән хатыны.

**Гайшә** (Аллаһ аннан риза булсын)

Сәүдәдән соң Пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) Гайшә Умм Габдуллаһка, Әбү Бәкер кызына, өйләнә. Ул Пәйгамбәрнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) яраткан хатыны булып, Аллаһ Тәгалә аның зинага катышы юклыгы хакында Коръәндә хәбәр итте. Гайшәгә өйләнгәнчегә кадәр, Пәйгамбәргә ике тапкыр төшендә ефәк кисәгендә аның сүрәте күрсәтелде һәм фәрештә: «Бу синең хатының!» - диде. Ул аңарга Шәүвәл аенда өйләнде, һәм ул вакытта Гайшәгә алты яшь иде. Тугыз яше тулгач, хиҗри буенча беренче елда, ул Пәйгамбәр белән бергә яши башлады. Аның башка хатыннары арасында бары тик ул гына гыйффәтле килеш кияүгә алынды. Аңа бары тик Гайшә белән генә ятакта ятканда Аллаһтан вәхий иңә иде, бүтән хатыннары белән булганда мондый хәл булмады. Аның өчен Гайшә бөтен җан ияләреннән иң яратканы булды. Ул күкләр биеклегеннән акланды. Ислам өммәтенең бердәм фикере шул: аны зина кылуда гаепләгән кеше имансыз була. Ул, Пәйгамбәребезнең барлык хатыннары арасында, Иман мәсьәләләре буенча иң гыйлемлесе. Һәм шулай да булгалый иде: Пәйгамбәребезнең иң хөрмәтле сәхәбәләре дә кайбер мәсьәләләрдә Гайшәгә мөрәҗәгать итәләр, аның сүзләрен дәлил итеп китерәләр иде.

**Хафсә (Аллаһ аннан риза булсын)**

Шуннан соң Пәйгамбәр (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Хафсә бинт Гомәр ибн әл-Хәттабка (Аллаһ аларның икесеннән дә риза булсын) өйләнде. Моңа кадәр Хафсә үзенең беренче хәләл җефете Хунайс ибн Хузафа әс-Сахми (Аллаһ аннан риза булсын) Ислам динен кабул иткән иде һәм аның белән бергә Мәдинәгә хиҗрәт кылган иде. Хунайс ибн Хузафа әс-Сахми Ухуд сугышыннан соң озак тормастан вафат булды, шуннан соң Пәйгамбәребез (Аллаһның аңа рәхмәте һәм сәламе булсын) Хафсәне хатынлыкка алды.

Зәйнәб бинт Хузәймә (Аллаһ аннан риза булсын)

Шуннан соң ул бәну Хиләл ибн Гамир нәселеннән булган Зәйнәб бинт Хузәймә ибн әл-Харис әл-Кайсийягә (Аллаһ аннан риза булсын) өйләнде. Ул Аллаһның рәсүле исән вакытта ук, өйләнешеп ике ай үткәч, вафат була. Зәйнәбне мескеннәрнең анасы (умм әл-мәсәкин) дип атаганнар.

**Умм Сәләмә** (Аллаһ аннан риза булсын)

Шуннан соң ул Умм Сәләмә Хинд бинт Әбу Умайя әл-Курашийя әл-Махзумийягә (Аллаһ аннан риза булсын) өйләнде. Аның этисенең исеме Әбу Умаййи. Ул Аллаһның рәсүленең барлык хатыннарына караганда да озаграк яшәде һәм хиҗри буенча 62нче елда вафат булды.

**Җөвәйрия** (Аллаһ аннан риза булсын)

Җөвәйрия бинт әл-Харис ибн Әбу Дирар әл-Мустәликийя (Аллаһ аннан риза булсын) бәну Мусталик кавеменә каршы походта әсирлеккә төшкән иде. Ул Аллаһның рәсүленә әсирлектән котылуда ярдәм итүен үтенеп мөрәҗәгать итте. Аллаһның илчесе аның өчен акча түләде һәм соңыннан аңа өйләнде.

**Зәйнәб бинт Джәхш**
(Аллаһ аннан риза булсын)

Шуннан соң Аллаһның рәсүле бәну Әсад ибн Хузәймә нәселеннән булган Зәйнәб бинт Джәхшкә (Аллаһ аннан риза булсын) өйләнде. Зәйнәб Пәйгамбәрнең әтисе ягыннан апасы булган Умайманың кызы. Аңарга карата ошбу аять иңә: "Зәйд аңа өйләнгәч һәм якынлык кылгач, (шуннан соң талак кылгач), (Зәйнәбнең талактан соң үтәргә тиешле вакыты үткәч) сине аңа өйләндердек,...". ("әл-Әхзаб" сүрәсе, 37нче аять). Һәм ул Пәйгамбәрнең башка хатыннары арасында моның белән горурлана иде һәм: "Сезне гаиләләрегез кияүгә бирсә, мине җиде күк биеклегеннән Аллаһ үзе кияүгә бирде", - ди иде.

Аның башкалардан аермасы шунда: ул Аллаһның рәсүленә кияүгә чыккан вакытта аның вәлие булып Аллаһ Тәгалә Үзе торды һәм Ул аны күкләр биеклегеннән кияүгә бирде. Ул Гомәр ибн әл-Хәттаб хакимлек итә башлаган чорда вафат булды. Гомерендә беренче тапкыр ул Аллаһның рәсүле кайчандыр уллыкка алган Зәйд ибн Хариска (Аллаһ аннан риза булсын) кияүгә чыккан иде. Зәйд аның белән аерылышкач, әлеге никах уллыкка алынган баланың элеккеге хатынына өйләнергә яраганлыкка мисал булып торсын өчен, Аллаһ Тәгалә аны Үзенең рәсүленә кияүгә бирде.

**Умм Хәбибә** (Аллаһ аннан риза булсын)

Шуннан соң Аллаһның рәсүле Умм Хәбибәгә (Аллаһ аннан риза булсын) өйләнде. Аның исеме - Рәмлә бинт Әбу Суфьян Сахр ибн Харб әл-Курайшийя әл-Әсадийя. Ул үзенең динен саклап калу өчен Эфиопия җиренә хиҗрәт кылган иде, Аллаһның рәсүле аңарга шул вакытта өйләнде. 400 динар күләмендәге никах бүләген рәсүлебез өчен Эфиопия патшасы Негус түләде һәм шуннан соң аны Аллаһның рәсүле янына алып килделәр. Ул үзенең абыйсы Мугавия (Аллаһ аннан риза булсын) хакимлек иткән чорда вафат булды.

**Сафийя** (Аллаһ аннан риза булсын)

Шулай ук ул Муса пәйгамбәрнең абыйсы Харун ибн Гыймран дәвамчысы булган бәну Надир кавеме башлыгы кызы Сафийя бинт Хуяй ибн Әхтабка да өйләнде. Сафийя (Аллаһ аннан риза булсын) – пәйгамбәр дәвамчысы һәм пәйгамбәр хатыны. Ул бөтен хатын-кызлар арасында иң чибәре иде. Ул Аллаһның илчесенә әсирлеккә төште һәм аның колы булды. Ул аны коллыктан азат итте һәм никах бүләге итеп азатлык бирде, һәм бу гамәл сөннәт гамәлләрдән булып санала башлады.

**Мәймүнә** (Аллаһ аннан риза булсын)

Шуннан соң ул Мәймүнә бинт әл-Харис әл-Хиләлийягә (Аллаһ аннан риза булсын) өйләнде. Ул Пәйгамбәребез өйләнгән соңгы хатын булды. Ул аңа тулыландыру гомрә хаҗын (гомрә әл-када) кылганнан соң ихрамнан чыккач өйләнде.

Вафат булган вакытында Пәйгамбәребезнең (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) тугыз хатыны булуы хакында галимнәр арасында фикер каршылыгы юк. Ул вафат булганнан соң, хатыннары арасында беренче булып хиҗри буенча 20нче елда Зәйнәб бинт Джәхш, ә соңгы булып хиҗри буенча 65нче елда, Йәзид бин Мугавия идарә иткән чорда, Умм Сәләмә (Аллаһ аннан риза булсын) вафат була.

# Икенче өлеш:
# АНЫҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ

| | | |
|---|---|---|
| Тууы | | Ул тарихка фил елы дип кереп калган елда Мәккәдә туа. Ул һиҗрәткә кадәр 53нче елда (милади буенча 571нче ел) Рабигуль-әүәл аенда дүшәмбе көнендә туа. Фил белән булган вакыйга, нәкъ менә Аллаһ Тәгаләнең Кәгъбәне җимерергә дип ниятләгән филне тотып калуы киләчәк Пәйгамбәр һәм аның гаиләсе өчен зур бер бүләк була. |
| Аның әтисе | | Габдуллаһ ибн Габдел-Мотталиб. Рәсүлебезнең әтисе ул әнисенең карынында вакытта ук вафат була, ул ятим туа. |
| Аның әнисе | | Бәну Зухра кабиләсеннән Әминә бинт Вәхб. Ул Пәйгамбәребезгә җиде яшь тулганчы вафат була. |
| Аның тәрбиячеләре | | Әнисенең вафатыннан соң аны бабасы Габдел-Мотталиб кайгырта. Булачак пәйгамбәргә сигез яшьләр чамасында бабасы да вафат була. Шуннан соң аны әтисе ягыннан абыйсы – Әбу Талиб, аның исеме Әбу Мәнәф була, тәрбиягә ала. |
| **Аның сөт аналары** | Сувәйбә | Әбу Ләхәб тарафыннан азат ителгән хатын. Үзенең улы Мәсрухны имезгән вакытта, булачак пәйгамбәр белән бергә, ул Әбу Сәләмә Габдуллаһ ибн Габдел-Әсәд әл-Мәхзумийны да (Аллаһ аннан риза булсын) имезә. Алар белән бергә ул шулай ук аның абыйсы Хәмзә ибн Габдел-Мотталибны да (Аллаһ аннан риза булсын) имезә. |
| | Хәлимә әс-Сәгъдийя | Ул булачак пәйгамбәрне үзенең улы Габдуллаһны имезгән вакытта имезә. Габдуллаһ – Унәйсә һәм Джүзәмәнең (аны шулай ук әш-Шәймә дип тә атаганнар) абыйлары, алар өчесе дә әл-Харис ибн Габд әл-Гуззә ибн Рифәг әс-Сәгъдийнең балалары. Шул ук вакытта Хәлимә пәйгамбәрнең абыйсының улы Әбу Суфьян ибн әл-Харис ибн әл-Мотталибны да имезгән. |
| **Аны караган хатыннар** | Әнисе Әминә | Сувәйбә, Әбу Ләхәб тарафыннан азат ителгән хатын. — Хәлимә бинт Әбу Зуәйб әс-Сәгъдийя |
| | әш-Шәймә | Хәлимә әс-Сәгъдийянең кызы һәм пәйгамбәрнең сөт апасы. Соңрак ул Пәйгамбәребез янына Хавазин кабиләсеннән делегация составында килә, һәм Пәйгамбәребез, аерым хөрмәт күрсәтеп, аның өчен дип, өстендәге япмасын җәя. |

## Аны караган хатыннар

### Умм Әймән

Бәракә әл-Хәбәшийяне (Эфиопияле) (Аллаһ аннан риза булсын) пәйгамбәребез әтисеннән мираска ала һәм ул аның әнисен бала таптыра. Пәйгамбәребез аны үзенең яраткан кардәше Зәйд ибн Хариска (Аллаһ аннан риза булсын) никахлый, һәм Умм Әймән аннан Усама ибн Зәйдне (Аллаһ аннан риза булсын) таба. Пәйгамбәребез вафатыннан соң берникадәр вакыт үткәч, Әбу Бәкр һәм Гомәр (Аллаһ аларның икесеннән дә риза булсын) Умм Әймән янына баралар. Алар килгәч, Умм Әймән елый башлый, һәм алар аннан: “Ник син елыйсың? Аллаһ хозурында булу Аллаһның рәсүле өчен яхшырак икәнлеген белмисеңме әллә?” – дип сорыйлар. Ул болай дип җаваплый: ”Чынлыкта, мин Аллаһ хозурында булу Аллаһның рәсүленә яхшырак булуын белмәгәнгә еламыйм, ә күкләрдән вәхий иңү тукталганга елыйм!” – бу сүзләр аның кунакларына шулкадәр тәэсир итә ки, алар да Умм Әймәнгә кушылып елый башлыйлар.

### Аның шөгыле

Булачак пәйгамбәр (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) сарык көтүен көтә һәм бу аның аеруча сабыр булуына һәм көчсезләрне кызгануына һәм кайгыртуына сәбәп була. Ул әйтте: “Аллаһ кешеләргә кайсы гына пәйгамбәрне җибәрмәсен, ул пәйгамбәр, һичшиксез, сарык көтүен көткән”. Сәхәбәләр аннан сорадылар: “Ә син?”, – һәм ул әйтте: “Әйе, мин дә берничә карат бәрабәренә (ягъни аз гына түләүгә) мәккәлеләр өчен сарык көтүен көттем”.

### Сәүдәсе һәм никахы

Аңа 25 яшь тулгач, ул сәүдә эшләре буенча Шәм шәһәренә юл тота. Ул Басра шәһәренә (хәзер Сириянең көньягында) җитә, ләкин шуннан кире кайта. Кайтуга ук ул Хәдичә бинт Хувайлидка (Аллаһ аннан риза булсын) өйләнә, Хәдичә аның беренче хатыны була.

### Кәгъбәне төзекләндерү

Аңа утыз биш яшь тулгач, башта янгыннан, аннан соң көчле ташкыннан Кәгъбә диварлары зур зыян күрә. Корәеш халкы Кәгъбәне төзекләндерергә карар кыла һәм һәр кабиләгә аерым бер өлеш бүлеп бирелә. Эш кара ташны үз урынына кире кайтаруга барып җиткәч, алар арасында бу ташны урынына кем куярга тиеш, дигән каршылык килеп туа һәм ул дүрт-биш көн дәвам итә. Шуннан соң алар әлеге низагны Кәгъбә ишек алды капкаларыннан беренче кергән кеше хәл итсен, дигән фикергә киләләр. Һәм бу кеше Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) булып чыга, алар аңа әлеге низагны хәл итү мәсьәләсен тапшыралар. Пәйгамбәребез япма сорап ала һәм шуның өстенә кара ташны куя, шуннан соң ул һәр кабиләдән берәр вәкил чакырып, аларга япма читләреннән тотарга һәм кара ташны алып барырга куша. Кара ташны Кәгъбә янына китереп җиткергәч, Мөхәммәд (Аллаһның аңа сәламе һәм рәхмәте булсын) үзенең куллары белән аны урынына урнаштыра.

Хәзерге вакытта кара таш Кәгъбәнең эчке әйләнәсеннән метр ярым биеклектә тора. Кәгъбәнең ишекләренә килгәндә исә, алардан керергә рөхсәт булган кешеләр генә үтә алсын өчен, ике метр биеклеккә күтәрәләр.

Кәгъбәнең диварлары да элеккегегә караганда ике тапкырга биегрәк итеп, унсигез терсәккә күтәртелеп төзелә. Ә мәчетнең эчендә ике рәткә алты багана утыртыла, алар унбиш терсәк биеклегендә түбә белән каплана. Ә элеккеге Кәгъбәдә баганалар да, түбә дә булмаган.

### Аның ялгызлыкта калуы

Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйткән: "Шуннан соң ул ялгыз калырга ярата торган булган. Һәм ул Хира тавындагы тау куышында ялгызы гына калып, бик күп төннәр дәвамында Аллаһка гыйбадәт кылу белән мәшгуль булган". Һәм аның күңеленә потларга һәм үзенең халкы тоткан дингә карата нәфрәт салына, һәм ул иң нәфрәтләнгән нәрсәләр дә шул иде.

# 2нче бүлек: Вәхий иңә башлау

Кырык яшь тулгач, аңарга Аллаһтан вәхий иңә башлый. Аллаһ Тәгалә Үзенең вәхийе белән аны дүшәмбе көнне олуглый.

**Аның пәйгамбәрлек миссиясе**

Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте, дип хәбәр итеlә:
– Аллаһның рәсүленә вәхий иңү яхшы, матур төш күрүеннән башлана, һәм аның әлеге төш кебек иртәнге таң аткан сыман кергән төшләрдән башка бүтән төрле төшләр күргәне булмады. Шуннан соң ул ялгыз калырга ярата торган булган. Һәм Хира тавындагы тау куышында ялгызы гына калып, гаиләсенә кайту теләге уянганчыга кадәр, бик күп төннәр дәвамында Аллаһка гыйбадәт кылу белән мәшгуль булган. Һәм, гадәттә, ул үзе белән бөтен кирәк-яракны ала торган булган. Шуннан соң янәдән ялгыз калу өчен кирәк-яраклар алырга дип, Хәдичә янына кайта торган булган. Аңа хакыйкать ачылганчыга кадәр шул рәвешле дәвам иткән.
Бервакыт Хира тавының куышында утырган вакытта аның янына фәрештә төшкән һәм :"Укы!" – дип әйткән, фәрештәгә җавап итеп ул: "Мин укый белмим!" – дигән.
(Пәйгамбәр) әйткән:
– Шулвакыт ул мине шундый итеп кочагына кысты ки, мин соң чиккә кадәр киерелдем, шуннан соң ул мине җибәрде һәм янәдән әйтте: «Укы!». Мин җаваплaдым: "Мин укый белмим!" Шунда ул мине икенче тапкыр кочагына кысты, мин янә соң чиккә кадәр киерелдем, ул мине җибәрде һәм әйтте: "Укы!" – һәм мин янәдән әйттем: "Мин укый белмим!" Шул чагында ул мине өченче тапкыр кочагына кысты, шуннан соң җибәрде һәм әйтте: **«Укы һәрнәрсәне бар кылучы Раббың исеме белән! Ул кешене оешкан каннан халык кылды. Укы, синең Раббың иң Юмартыдыр..."**
(Гайшә, Аллаһ аннан риза булсын, әйтте):
– Һәм йөрәге куркудан калтыраган рәсүлебез Хәдичә бинт Хувайлид, Аллаһ аннан риза булсын, янына кайткан һәм: «Ябындырыгыз мине, ябындырыгыз мине!», - дигән. Шул сүзләреннән соң аны ябындырганнар һәм ул куркуы тәмам үткәнчегә кадәр шул халәтендә калган. Куркуы үткәч, ул барысы хакында да Хәдичәгә сөйләгән һәм: «Мин үзем өчен курыктым!» - дигән. Хәдичә аңа җавап итеп: "Юк, юк! Аллаһ белән ант итәм, Аллаһ сине беркайчан да хурлыкка калдырмаячак, син бит туганлык җепләрен өзмисең, зәгыйфьләргә булышасың, фәкыйрьләргә өләшәсең, кешеләргә кунакчыллык күрсәтәсең һәм аларга язмыш авырлыкларын җиңәргә ярдәм итәсең!» - дигән. Шуннан соң Хәдичә пәйгамбәребез белән бергә йортыннан чыккан һәм аны ике туган абыйсы Варака бин Нәүфәл бин Әсәд бин Габд әл-Үззә янына алып килгән. Ул җәһилият заманында христиан динен кабул итеп, яһүдиләр язуыннан куллана һәм Инҗилдән Аллаһ теләгән нәрсәләрне күчереп яза иде. Ләкин ул вакытка ул инде сукырайган һәм бик картайган булган. Хәдичә аңарга әйткән: "Әй минем абыемның угылы, үзеңнең бертуганыңның угылын тыңла әле!" Варака сораган Пәйгамбәрдән: "Әй бертуганымның угылы, син нәрсәләр күрдең?" – һәм Аллаһның рәсүле аңарга күргәннәре хакында сөйләп биргән. Варака: "Бу Аллаһ Мусага җибәргән фәрештә! Мин бүген яшь булып, халкың сине куып җибәргән чорга кадәр яши алсам әгәр!" – дигән. Аллаһның рәсүле: "Алар мине куып җибәрәчәкләрме әллә?" – дип сораган. Варака: "Әйе, синең кебек халыкларга хаклык белән килгән һәркемне шулай дошман күрделәр. Тик мин шул көннәргә кадәр яши алсам, ничек булдыра алам, шулай сиңа ярдәм итәчәкмен!" – дип җавап биргән.
Әмма Варака тиздән вафат була, ә вәхий иңү вакытлыча туктатыла.

| Аның пәйгамбәрлек миссиясе | |
|---|---|
| | – Аллаһның рәсүле ﷺ әйтте: “(Бервакыт) мин (юлдан) бара идем һәм кинәт күктән тавыш ишеттем. Мин башымны күтәрдем һәм мин Хира тавындагы куышта булганда беренче тапкыр яныма килгән фәрештәне күрдем, ул (бу юлы) күк белән җир арасында тәхеттә утыра иде. Мин аннан курыктым, (өемә) кайттым һәм: “Ябындырыгыз мине, ябындырыгыз мине!” – дидем, шуннан соң Аллаһ Тәгалә түбәндәге аятьләрне иңдерә: **“Ий бөркәнгән! Тор һәм кешеләрне Аллаһ газабы белән куркыт! Раббыңны зурлап тәкбир әйт. һәм киемеңне нәҗәсәттән пакь кыл...”** Шушы вакыйгадан соң вәхий иңү яңа көч белән һәм бер-бер артлы иңә башлый. |

**Вәхийнең дәрәҗәләре**

| Вәхийнең дәрәҗәләре | | |
|---|---|---|
| | **(1) Хак төш** | Пәйгамбәребезгә ﷺ вәхий иңү дә төштән башлана. Гайшә (Аллаһ аннан риза булсын) әйтте: "Аллаһның рәсүленә вәхий иңү яхшы, матур төш күрүеннән башланган, һәм аның әлеге төш кебек иртәнге таң аткан сыман кергән төшләрдән башка бүтән төрле төшләр күргәне булмаган". |
| | **(2) Йөрәгенә, калебенә салу** | Кайвакыт фәрештә вәхийне Пәйгамбәребезнең ﷺ йөрәгенә, калебенә сала иде, ул бу вакытта фәрештәне күрми иде. Ул ﷺ әйтте: "Дәреслектә, Җәбраил фәрештә минем йөрәгемә өрде һәм миңа ... хакында хәбәр бирде”. |
| | **(3) Фәрештәнең кеше кыяфәтендә килүе** | Пәйгамбәр ﷺ әйтте: "Кайвакытта фәрештә минем каршыма кеше кыяфәтендә килә һәм сөйли, ә мин ул сөйләгәнне отып барам". Кайвакытта сәхәбәләр дә кеше кыяфәтендәге фәрештәне күрәләр иде. |
| | **(4) Кыңгырау чыңы сыман** | Пәйгамбәр ﷺ әйтте: "Кайвакытта вәхий иңү кыңгырау чыңы сыман була, бу минем өчен иң авыры, әйтелгәнне отып алгач, кыңгырау чыңы туктый".<br>Гайшә (Аллаһ анан риза булсын) әйтте: "Миңа да салкын көннәрдә аңа ﷺ вәхий иңүен күрергә туры килде, вәхий иңү тәмам булганнан соң, һәрчак аның маңгаеннан тир агып тора иде". Дөя өстендә булганда вәхий иңсә, дөя тезләнә иде. |
| | (5) Фәрештәнең үз кыяфәтендә килүе | Пәйгамбәр ﷺ шулай ук фәрештәне Аллаһ аны халык кылган кыяфәтендә дә күрә. Фәрештә аңарга Аллаһ төшендерергә теләгән нәрсәләрне күңеленә сала. Мондый хәл ике тапкыр кабатлана, бу хакта Аллаһ “ән-Нәҗм” (Йолдыз) сүрәсендә әйтә. |
| | (6) Аллаһтан вәхий килүе | Бу вакытта вәхий аның күңеленә турыдан-туры Аллаһ Тәгаләдән салына. Күккә күтәрелү төнендә – Пәйгамбәребез ﷺ күкнең җиденче катыннан өстәрәк булып, биш вакыт намаз һәм башка нәрсәләр фарыз ителгән вакытта нәкъ шулай була. |
| | (7) Аллаһның аңа мөрәҗәгать итүе | Бу вакытта Аллаһ Тәгалә аның белән арадашчыларсыз, Муса пәйгамбәр (галәйһиссәләм) белән сөйләшкән кебек сөйләшә. |

| Аңа беренче булып иңгән вәхий | «Әл-Галәк» (Оешкан кан) сүрәсенең беренче биш аяте: **"1. Укы һәрнәрсәне бар кылучы Раббың исеме белән! 2. Ул кешене оешкан каннан бар кылды. 3. Укы, синең Раббың иң Юмартыдыр, 4. Ул – Аллаһ каләм белән язуны өйрәтте, 5. кешегә белмәгән нәрсәләрен өйрәтте".** |
|---|---|

**Аның чакыруының дәрәҗәләре**

(1) Пәйгамбәрлеге

(2) Үзенең якын туганнарын үгетләве

(3) Үзенең халкын үгетләве

(4) Аңа кадәр бер үгетләүче дә килмәгән халыкны, ягъни барлык гарәпләрне дә үгетләве.

(5) Бу дөньяның ахырына кадәр, аның чакыруы барып ирешкән җеннәрдән һәм кешеләрдән булган барысын да үгетләве.

**Аның чакыруының баскычлары**

(1) Яшерен чакыру: пәйгамбәрлегенең беренче өч елы.

(2) Ачыктан-ачык чакыру **"Инде ислам динен изһар кыл! Кешеләрне иманга вә Коръән белән гамәл кылырга ачыктан-ачык өндә! Вә мөшрикләрдән ерак бул!"** (“әл-Хиҗр” сүрәсе, 94нче аять) аяте иңгәч башлана.

**Аңа, пәйгамбәр буларак, беренче иман китерүчеләр**

| | |
|---|---|
| Ир-атлардан: Әбу Бәкр әс-Сиддыйк. | Хатын-кызлардан: Хәдичә бинт Хувайлид. |
| Балалардан: Гали ибн Әбу Талиб. | Коллыктан азат ителгәннәрдән: Зәйд ибн Харисә. |
| Коллардан: Биләл ибн Рабәх әл-Хәбәши. | |

**Беренчеләрдән булган кайберәүләр**

Аңа, пәйгамбәр буларак, беренчеләрдән булып (аның гаилә әһелләреннән соң) иман китергән кешеләр: Госман ибн Гаффән, Тальха ибн Гобәйдуллаһ, әз-Зөбәйр ибн әл-Гаввәм, Са’д ибн Әбу Вәккас, Габдеррахман ибн ‘Ауф, Хаббәб ибн әл-Әрат, Сухайб әр-Руми, ‘Аммәр ибн Йәсир һәм аның әнисе Сөмәйя, Әбу ‘Убәйда ‘Әмир ибн әл-Джәррах, ‘Усман ибн Мәз’ун, Әбу Сәләмә ибн Габдел-Әсад һәм ‘Утба ибн Газван, Аллаһ аларның барысыннан да риза булсын.

# 3нче бүлек: Мәккә чоры

**Мөшрикләрнең Пәйгамбәребезгә һәм аның сәхәбәләренә җәфа-газаплар күрсәтүе**

Пәйгамбәребезнең ﷺ чакыруы хак булганын һәм кешеләрнең аның янәшәсенә тупрлануын күргәч, мөшрикләр мөэминнәргә җәфа-газаплар күрсәтә башлый. Менә кайбер мисаллар:

– Мөхәммәд ﷺ хакында, кешеләрнең аңардан күңеле кайтсын, аңардан курыксыннар өчен, сихерче дигән хәбәр тараталар.

– Мөхәммәд ﷺ хакында, кешеләр аны акылга сай дип уйласын өчен, юләр дигән хәбәр тараталар.

– Мөхәммәдне ﷺ ялганчы дип хәбәр тараталар. Ләкин мөшрикләрнең бу ялганнары барып чыкмый, чөнки ул ﷺ кешеләр арасында үзенең хак сөйләве һәм ышанычлы булуы белән ышанычлы (әл-әмин) буларак билгеле була инде.

– Пәйгамбәребездән ﷺ һәм ул алып килгән хак диннән мыскыл итеп көләләр.

– Пәйгамбәребез ﷺ Аллаһтан вәхий белән яки башка төрле хаклык белән килгән вакытта, кешеләр аны тыңламасыннар, игътибарлары читкә юнәлсен өчен төрле ыгы-зыгы, тавыш-гауга китереп чыгаралар.

– Мәккәгә гомрә хаҗына яки олы хаҗга килүчеләрне, Пәйгамбәребез ﷺ белән очрашмасын дип, яки кисәтеп кую өчен, үзләре каршы алалар.

– Пәйгамбәребезнең ﷺ шәхсән үзенә җәбер-золым кылалар. Мәсәлән, бервакыт ‘Укба ибн Әбу Му’әйт, Пәйгамбәребезне киеменнән әләктереп алып, аны буа-буа үзенә таба тарта. Әбу Бәкр аны этеп җибәреп, Пәйгамбәребезне коткара. Шулай ук ул Пәйгамбәребез сәҗдәдә булган вакытта, мөшрикләр корбан итеп чалган ана дөянең яралгысының «күлмәген» аның аркасына сала. Бу золымнан аны кызы Фатыйма коткара.

– Пәйгамбәребезне ﷺ үтерергә күп тапкырлар омтылышлар ясыйлар. Мөшрикләр аның агасы Әбу Талибка Пәйгамбәребезне ﷺ ‘Әмәра ибн әл-Вәлид исемле кешегә алыштырырга тәкъдим итәләр, аларның ниятләре Пәйгамбәребезне ﷺ үтерү була, әмма Әбу Талиб бу тәкъдимнән баш тарта. Шулай ук аны, һиҗрәт кылырга ният кылган вакытында да үтерергә телиләр.

– Ярдәм итәргә кешеләре булмаган мөэминнәргә каты газаплар китерәләр. Мәсәлән, алар Биләлнең корсагына авыр таш куялар, ‘Әммәр бин Йәсирнең гаиләсен дә һәм башка мөэминнәрне дә каты газапларга дучар итәләр.

**Эфиопиягә һиҗрәт**

Мөселманнар күбәеп киткәч һәм мөшрикләр, куркып, аларны тагын да катырак газапларга керешкәч, Аллаһның рәсүле ﷺ аларга Эфиопиягә һиҗрәт кылырга рөхсәт бирә. Ул әйтте: **“Чынлыкта, ул илнең патшасы хакимлек иткән чорда кешеләр җәберләнмиләр”.**

## Эфиопиягә һиҗрәт

### Беренче һиҗрәт

Беренче мәртәбә Эфиопиягә 12 ир-ат һәм 4 хатын-кыз һиҗрәт кыла. Алар арасында Усман бин Аффан رضي الله عنه була. Ул һиҗрәт кылучылардан беренче булып Мәккәдән чыга, аның белән хатыны – Пәйгамбәребезнең ﷺ кызы Рукайя да була. Эфиопиядә алар бик яхшы шартларда яшиләр. Бервакыт аларга көрәешләр Ислам динен кабул иттеләр, дигән хәбәр килеп ирешә. Ләкин, соңрак ачыкланганча, ул хәбәр ялган булып чыга. Әмма алар инде Мәккәгә кайтып җиткән булалар. Аларның кайберләре, Мәккәгә керергә кыймыйча, кире Эфиопиягә китеп бара, ә кайберләре исә Мәккәгә керә. Мәккәгә кергән мөселманнар (алар арасында Габдуллах ибн Мәс’уд رضي الله عنه тә була) көрәешләрдән нык җәбер-золым, җәфалар күрәләр.

### Икенче һиҗрәт

Икенче мәртәбәдә Эфиопиягә 83 ир-ат һәм 18 хатын-кыз күченә. Алар Эфиопиядә Негус патша вакытында яшиләр. Бу хактагы хәбәр көрәешләргә барып ирешә һәм алар Эфиопиягә берничә кешене, алар арасында Әмр ибн әл-‘Әс һәм Габдуллаһ ибн Раби’ә да булды, җибәрәләр. Мөшрикләрең ниятләре мөселманнарга карата Негус патшаның мөнәсәбәтен үзгәртү иде. Ләкин Аллаһ Тәгалә аларның хәйләләрен үзләренә каршы юнәлтте.

## Гомәр һәм Хәмзәнең Ислам динен кабул итүләре

Пәйгамбәрлек миссиясенең алтынчы елында Ислам динен көрәешләр арасында иң көчле кеше дип йөртелгән Хәмзә ибн Габдел-мотталиб та رضي الله عنه кабул итә. Аллаh Тәгалә аның аркылы Үзенең рәсүлен ﷺ ныгыта. Шуннан соң Гомәр ибн әл-Хәттаб та رضي الله عنه Ислам динен кабул итә, аның өчен Пәйгамбәребез ﷺ Аллаhка дога белән мөрәҗәгать итә. Хәмзә белән Гомәр Ислам динен кабул иткәч, мөэминнәрнең көче арта, ә корәешләр мөэминнәргә карата дошманлыкларын бераз киметәләр.

## Әбу Талиб мәгарәсендә

Корәешләр Алаhның рәсүленә ﷺ тагын да катырак җәфа китерергә тели һәм Әбу Талиб мәгарәсендә аңа һәм аның гаиләсенә камау, чолганыш оештыра. Бу камап тору өч ел дәвам итә. Мәгарәдә чолганыш вакытында Габдуллаh ибн Аббас رضي الله عنه туа. Әлеге камалыш Пәйгамбәребез ﷺ өчен бик авыр сынау була. Бу камалыш тәмамланганда аңа 49 яшь була.

## Әбу Талиб һәм Хәдичәнең вафат булулары

Әлеге вакыйгадан соң бер ай үткәч, Пәйгамбәребезнең агасы 87 яшьлек Әбу Талиб бакыйлыкка күчә. Шуннан соң берникадәр вакыттан соң аның хәләл җефете Хәдичә дә رضي الله عنها вафат була. Корәешләр тарафыннан Пәйгамбәребезгә ﷺ карата җәфалар тагын да көчләнеп китә.

## Таиф шәһәренә баруы

Бервакыт Пәйгамбәребез ﷺ Зәйд ибн Харисә белән, кешеләрне Аллаh Тәгаләгә чакыру өчен, Таиф шәһәренә юл тоталар. Аллаhның рәсүле анда берничә көн тора, әмма Таиф шәһәре халкы аның чакыруына җавап бирми. Киресенчә, аңарга карата нык золымлык кыла: халык рәсүлне ташлар атып шәһәрдән куып чыгара, хәтта аның аяк табаннарына кадәр яраланып бетә. Аллаhның рәсүле Таифтан китә һәм Мәккәгә кире кайтырга уйлый, шәһәргә ул әл-Мут’им ибн ‘Адий яклавы астында керә.

| | | |
|---|---|---|
| **‘Аддас һәм аның Ислам динен кабул итүе** | | Мәккә шәһәренә кайтышлый ул ‘Аддас исемле христанны очрата, ‘Аддас аңа иман китерә һәм аны пәйгамбәр итеп таный. |
| **Җеннәрнең иман китерүе** | | Юлда, Нәхлә дигән урында аңа бер төркем нәсыбиййун кабиләсе җеннәре җибәрелә. Алар җидәү булалар. Алар Коръән тыңлыйлар һәм Ислам динен кабул итәләр. |
| **Исра һәм Миграҗ** | | Шуннан соң ул төнлә җаны вә тәне белән Иерусалимдагы әл-Акса мәчетенә кучерелә һәм шуннан җаны вә тәне белән күкләрдән дә югарырак Аллаһ Тәгалә тарафына күтәрелә. Аллаһ Тәгалә аңа мөрәҗәгать итеп сөйли һәм биш вакыт намазны фарыз итә. |
| **Гарәп кабиләләренә Ислам динен тәкъдим итүе** | | Мәккәдә яшәп, ул гарәп кабиләләрен Аллаһ Тәгаләгә чакыра алсын һәм Раббысының сүзен халыкларга җиткерә алсын өчен, үзен аларның яклавы астына алырга тәкъдим итә. Моның өчен аларга Җәннәт вәгъдә ителә. Ләкин бер кабилә дә аның тәкъдименә җавап бирми, Аллаһ Тәгалә әлеге хөрмәтне ансарларга калдыра. Әлеге хәбәр ансарлардан булган алты кешегә ирешә һәм алар Аллаһка һәм Аның рәсүленә җавап бирәләр. Алар Мәдинәгә кайталар һәм кешеләрне Исламга чакыра башлыйлар. Һәм Мәдинә халкы арасында Ислам дине шул дәрәҗәдә тарала ки, хәтта Мәдинәдә Пәйгамбәребез хакында сөйләмәгән бер генә йорт та калмый. |
| **Ансарлар һәм әл-Акабада ант бирү** | **Беренче ант** | Ошбу вакыйгалардан соң икенче елга Мәккә шәһәренә ансарлардан булган унике ир-ат килә. Аларның бишесе иң беренче алты кеше арасыннан була. Алар Аллаһның рәсүленә әл-Акаба янында ант бирәләр. Әлеге ант “әл-Мумтәхәнә” сүрәсендә хатын-кызларга тәкъдим ителгән иде. Шуннан соң алар Мәдинәгә кайтып китәләр. |
| | **Икенче ант** | Янәдән бер елдан соң Мәдинәдән 73 ир-ат һәм 2 хатын-кыз килә. Алар Аллаһның рәсүленә аны хатыннарын, балаларын һәм үзләрен яклаган кебек яклаячакларын әйтеп, ант бирәләр. Шуннан соң Аллаһның рәсүле һәм аның сәхәбәләре алар янына килеп, алар арасыннан 12 җитәкчене сайлап куя. |

# 4нче бүлек: Мәдинә чоры

### Һиҗрәт кылырга рөхсәт

Аллаһның рәсүле ﷺ үзенең сәхәбәләренә Мәдинәгә һиҗрәт кылырга рөхсәт бирә. Сәхәбәләр Мәккәдән кечкенә генә төркемнәр белән яшерен рәвештә китәләр. Беренче һиҗрәт кылучы яки Әбу Сәләмә ибн Габд әл-Әсад әл-Мәхзуми, яки Мус’аб ибн Умайр була. Ансарлар аларны яшәү урыннары белән тәэмин итәләр һәм һәрдаим булышып торалар. Шул рәвешле Мәдинәдә Ислам дине тарала.

Шуннан соң Аллаһ Тәгалә Үзенең рәсүленә һиҗрәт кылырга рөхсәт бирә. Ул Мәккәдән Рабигуль-әүүәл аеның дүшәмбесендә чыга, бу вакытта аңа 53 яшь була. Аның белән бергә Әбу Бәкр һәм Әбу Бәкр тарафыннан азат ителгән ‘Амир бин Фухайра булып, алар юлга кузгала. Аларның озатып баручылары Габдуллаһ ибн Урайкит әл-Ләйси була. Аллаһның рәсүле һәм Әбу Бәкр  Саур тавының куышында өч көн дәвамында качып утыра һәм шуннан соң,  диңгез яры буйлап сузылган юлдан, Мәдинәгә юнәлә.

### Пәйгамбәрнең Мәдинәгә керүе

Пәйгамбәребез ﷺ үзенең юлдашы белән Рабигуль-әүүәл аеның 12сендә дүшәмбе көнне Мәдинәгә килеп җитәләр һәм Мәдинә шәһәренең югары өлешендәге Куба дигән җирдә туктыйлар, Әмр ибн Әуф  кабиләсендә ундүрт көн кунак булалар.

### Исламдагы беренче мәчет

Пәйгамбәребез ﷺ Куба мәчетенә нигез сала. Ибн Умар әйтте: **"Пәйгамбәребез ﷺ һәр шимбә саен Куба мәчетенә бара иде".** Пәйгамбәребез дә ﷺ әйтте: **"Куба мәчетендә укылган намаз гомрә хаҗына тиң".**

### Пәйгамбәребез мәчетен төзү

Шуннан соң Пәйгамбәребез ﷺ үзенең дөясенә утыра һәм юлга кузгала. Юлда барганда кешеләр аның дөясенең тезгененнән тотып, үзләренә кунакка чакыралар иде. Ул исә: "Дөямә юл бирегез, аңа фәрман күктән бирелә”, - дия иде. Шуннан соң дөя хәзерге вакытта Пәйгамбәребез мәчете урнашкан җирдә туктый һәм тезләнә. Бу җир кисәге бәну Нәдҗәр кабиләсеннән булган Сәхл һәм Сухәйл исемле ике ятим малайныкы иде. Пәйгамбәребез Әбу Әййуб әл-Ансари йортында туктала. Шуннан соң әлеге урында мәчет төзелеше башланып китә. Әлеге төзелештә, сәхәбәләр белән берр әттән, Пәйгамбәребез дә ﷺ катнаша. Мәчетне кызыл балчыктан һәм пальма агачы ботакларыннан төзиләр. Шуннан соң мәчетнең диварларына терәп, Пәгамбәребезнең үзе һәм аның хатыннары өчен бүлмәләр төзелә. Аның бүлмәсенә иң якын бүлмә Гайшәнеке була. Җиде ай үткәннән соң, ул үзенең гаиләсе белән, Әбу Әййуб йортыннан үз торагына күченә.

**Туганлашу**

Мәчет төзелешеннән соң, Пәйгамбәребез ﷺ мөһаҗирләр (алар 90 ир-ат була) һәм ансарларны туганлаштыра. Бу үз милкен югалткан мөһаҗирләргә бер юаныч була, чөнки туганлашкан кешеләрнең берәрсе вафат булган очракта, аның мирасы, кан туганнары белән беррәттән, туганлашканнарның икенчесенә дә бүленә. Мондый халәт Бәдр сугышына кадәр саклана.

**Яһүдиләр**

Пәйгамбәребез ﷺ Мәдинәгә килгәч, аны күргән яһүдиләр аның Тәүратта бәян ителгән Аллаһның хак рәсүле икәнлеген аңлыйлар. Әмма шуңа да карамастан, аларның күбесе Ислам динен кабул итми. Бары тик беразы гына, алар арасында төрле язмалар хакында күп белүче галим Габдуллаһ бин Сәләм, Исламны кабул итә. Һәм Пәйгамбәребез ﷺ бәну Кайнука', бәну Надир һәм бәну Курайза яһүд кабиләләрен татулаштыра.

**Кыйбланың үзгәрүе**

Аллаһ Тәгалә биш вакыт намазны фарыз иткән Миграҗ төненнән соң, Пәйгамбәребез ﷺ намазларын Иерусалим ягына юнәлеп укый иде. Ул Аллаһ Тәгаләнең кыйбла юнәлешен Кәгъбә ягына таба үзгәртүен тели һәм, шуңа өметләнеп, бик еш карашларын күккә юнәлтә иде. Һәм менә һиҗрәттән соң икенче елда Аллаһ Тәгалә ошбу аятьне иңдерә: **"Әлбәттә, күрәбез йөзеңне күккә күтәреп торуыңны. Һәм, әлбәттә, сине үзең теләгән Кәгъбәттуллага юнәлдерербез** ("әл-Бәкара" сүрәсе, 144 аять)". Һәм Аллаһ Тәгалә кыйбланы Кәгъбә юнәлешенә таба үзгәртә.

**Җиһәд кылуга рөхсәт**

Пәйгамбәребез ﷺ Мәдинә шәһәренә күченгәннән соң, ансарлар аны дошманнардан саклап тора. Аллаһ Тәгалә ошбу аятьне иңдерә: **"Кәферләр өстенә сугыш белән барырга мөэминнәргә Аллаһтан рөхсәт бирелде, кәферләрдән золым күргәннәре өчен, дөреслектә Аллаһ мөэминнәргә ярдәм бирергә кодрәтле. Ул кәферләрдән золым күрүче мөэминнәр: "Безнең Раббыбыз Аллаһ", – дип әйткән өчен йортларыннан куылдылар.** ("Хаҗ" сүрәсе, 39-40нчы аятьләр), һәм Аллаһ Тәгалә мөшрикләр белән сугыш алып барырга рөхсәт бирә.
Абва, Буват, әл-'Ушайра һәм башка походлар беренче походлардан була.

**Бәдр янындагы сугыш**

Һиҗри исәп буенча икенче елның Рамазан аенда Аллаһның рәсүле мөэминнәрдән булган өч йөздән артык хәрби белән, корәешләрнең Шамнан кайтучы кәрваннарын эзләп, Мәдинәдән чыга. Кәрванның башлыгы Әбу Суфьян, Аллаһның рәсүленең ниятен белеп, аның отряды белән очрашудан качу өчен юлны үзгәртә. Мәккәдә исә шәйтан корәешләрне мөселманнарга каршы сугышка күтәрелергә котырта. Ике гаскәр Бәдр дигән җирдә очраша, нәкъ менә биредә олуг сугыш була. Әлеге сугыш булган көнне икенче төрле "йәум әл-фуркан" (Фуркан көне, Фуркан - аеру, хакны ялганнан аера торган һәрнәрсә фуркан дип йөртелә) дип тә атыйлар. Ике гаскәр очрашкач, Аллаһның рәсүле Раббысыннан ярдәм сорап, дога белән мөрәҗәгать итә. Аллаһ мөселманнарга ярдәмгә фәрештәләрне җибәрә, ул фәрештәләр мөселманнар белән рәттән басып сугыша. Аллаһ Тәгалә Үзенең Сүзен өстен итә, мөэминнәргә җиңү бирә. Бәдр сугышында мөшрикләр ягыннан 70 кеше һәлак булса, мөэминнәрдән 14 кеше шәһит китә.

**Кайнука’ ка поход**

Һиҗри буенча өченче елда Кайнука’ кабиләсе солых килешүен боза. Пәйгамбәребез, үзенең гаскәре белән, аларны 15 көн дәвам иткән камалышта калдыра. Шуннан соң бәну Кайнука’ Пәйгамбәребезгә әсирлеккә төшә. Ул аларны азат итәргә карар кыла. Әсирләр җиде йөз кеше була.

**Өхед янындагы сугыш**

Шул ук елның Шәүәл аенда Өхед тавы янында сугыш була. Корәешләр Бәдр сугышында һәлак булган кардәшләре өчен үч алмакчы булалар. Өч мең сугышчыдан торган Корәеш гаскәре Мәдинә янына килеп баса. Пәйгамбәребез ﷺ мең кешедән торган гаскәр белән Мәдинәдән чыгып, Өхед тавына таба юнәлә. Шул вакытта өч йөзләп монафыйк гаскәрне калдырып кача, һәм сугыш башланганчы мөэминнәр ягында нибары җиде йөзләп кеше кала. Көн башында өстенлек мөэминнәр ягында була, ләкин Аллаһ Тәгалә аларга сынау җибәрә һәм өстенлекне мөшрикләр гаскәренә бирә. Алар хәтта Аллаһның рәсүлен куып җитәләр, башын яралыйлар һәм тешен сындыралар. Бу көнне шулай ук мөэминнәр ягында фәрештәләр дә сугыша. Әлеге сугышта җитмеш сәхәбә башын сала, алар арасында Хәмзә бин Габдел-Мотталиб, Мус’аб ибн ‘Умайр, Әнәс ибн ән-Нәдр, Хәнзәлә әл-Гасыйл һәм башкалар була.

Әлеге сугышта Тальха бин Убайдуллаһ аеруча тырышлык күрсәтә, Аллаһның рәсүле ﷺ аның хакында: "**Тальха һичшиксез Җәннәтле**", - дип әйтә.

Шуннан соң Аллаһның рәсүле һәм мөэминнәрнең кечкенә бер төркеме Өхед тавы янына чигенә, аларга зыян салырга Аллаһ Тәгалә мөшрикләргә мөмкинчелек бирми.

Өхед тавы янындагы сугыш имтихан көне була: мөэминнәр сынала, монафыйклар ачыклана, шәһит киткән мөселманнар Аллаһтан ихтирам ала.

Әлеге сугыштан соң, Аллаһның рәсүле корәешләрнең, мөселманнарны тар-мар китереп бетерү нияте белән, янәдән гаскәр белән әйләнеп килүләре хакында хәбәр ала һәм аларга гаскәр белән үзе каршы чыгарга карар кыла. Мөселманнар Хамра әл-Әсад дип аталган җиргә җиткәч, бу хакта мөшрикләргә билгеле була. Шуннан соң Мәккә сугышчылары тәвәккәллекләрен югалта, алар куркуга кала һәм юлларын дәвам итеп, Мәккәгә кайтырга карар кыла.

**Һиҗри буенча дүртенче ел**

Һиҗри буенча дүртенче елда Бир Ма’ундә фаҗига була: биредә җитмеш сәхәбә – Коръән укучылар үтерелә. Шулай ук мөселманнар бәну ән-Нәдирга хәрби поход белән чыгалар, Пәйгамбәребез аларга камалыш оештыра. Шуннан соң Аллаһ аларның йөрәкләренә курку сала, һәм Пәйгамбәребез аларны Мәдинәдән куып чыгара. Алар хакында “әл-Хәшер” (Сөреп чыгару) сүрәсе иңә.

**Әл-Мурайси’ка поход**

Һиҗри буенча бишенче елда Пәйгамбәребез ﷺ бәну әл-Мусталик кавеменә каршы походка чыга һәм аннан җиңүче булып кайта. Әлеге походта булганда җир белән чистарыну кагыйдәсе – тәяммум кертелә. Әлеге походта шушындый вакыйга була: монафыйклар мөэминнәрнең анасы Гайшә хакында, аны зина кылуда гаепләп, ялган тарата. Әмма Гайшә анабыз әлеге гөнаһтан пакь була. Әлеге ялган сүзләр Гайшәнең дә Аллаһның рәсүленең дә күңелләрен нык төшерә. Аллаһ Тәгалә Гайшәнең әлеге гөнаһка катышы юклыгы хакында “Ән-Нур” сүрәсе аятьләрен иңдерә. Ә аның хакында бохтан таратучылар исә шәригать буенча хөкемгә – камчы белән суктырылуга хөкем ителә.

**Хандак сугышы**

Яһүдиләр, корәешләр һәм аларга союздаш булган кабиләләр Пәйгамбәребез ﷺ һәм аның сәхабәләре белән сугышырга карар кыла һәм һиҗри буенча бишенче елның Шәүәл аенда хандак сугышы була. Корәешләрдән, бәну Сулейм, бәну Әсад, Фазара, Ашджа’ һәм башка кабилә халыкларыннан торган ун меңлек гаскәр Мәдинәгә юнәлә.
Сәлмән әл-Фәриси Пәйгамбәребезгә дошманнардан саклану өчен зур чокыр казырга киңәш итә. Аллаһның рәсүле өч мең сугышчыдан торган гаскәр белән чыга һәм ныгытма сыйфатында Саль’ тавын сайлый, тауның алгы ягына зур чокыр казыла. Әлеге вакыйгаларга кадәр үк инде Пәйгамбәр ﷺ бәну Курайза дигән яһүди кабиләсе белән иминлек хакында солых килешүе төзегән була. Әмма яһүдиләр әлеге килешүне бозып, Пәйгамбәргә каршы чыкканнарга кушылалар. Шуннан соң Пәйгамбәр бәну Курайза яһүдиләренә, ә соңрак корәешләргә Ну’айм ибн Мәс’удне җибәрә, хәйлә ярдәмендә алар арасын боза. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә аларга көчле җил җибәрә, бу җил аларның палаткаларын һәм казаннарын әйләндереп сала. Ул аларны «дер» селкетә, аларның йөрәкләренә курку сала һәм сугышырга теләкләрен сүндерә. Пәйгамбәргә каршы чыккан гаскәр, үз максатына ирешә алмыйча, Мәдинәдән чыгып китә.
Шуннан соң Пәйгамбәребез ﷺ бәну Курайзага поход белән чыга, һәм Са’д ибн Му’аз аларга карата үзенең карарын чыгара. Чокыр янындагы сугыш хакында «әл-Әхзәб» сүрәсе иңә.

**Әл-Худайбийя янында солых килешүе**

Һиҗри буенча алтынчы елда Пәйгамбәребез ﷺ гомрә хаҗын үтәү өчен 1400 сәхабә белән Мәдинәдән чыга. Алар әл-Худайбийягә җиткәч, корәешләр аларны Мәккәгә кертүдән баш тарталар. Һәм Пәгамбәребез алар белән ун елга солых килешүе төзи һәм бу мөселманнар өчен зур җиңү була, Аллаһ Тәгалә әйтә: **"Шиксез, Без сиңа ачтык вә хөкем иттек ачык булган җиңүне"** (“әл-Фәтех” сүрәсе, 1нче аять).
Әлеге килешүдә шулай ук корәешләрнең алдагы елга да мөселманнарга гомрә хаҗын үтәргә рөхсәт итүләре хакында язылган була. Һәм һиҗри буенча җиденче елда Зөл-кагъдә аенда каза кылу гомрәсе (‘умра әл-када) кылына.

**Хәйбәргә поход**

Худайбийядән кайткач егерме көннән соң, Пәйгамбәребез Мәдинәдән төньяктарак урнашкан Хәйбәргә яу белән чыга. Мөселманнар Хәйбәрдә яһүдиләрне егерме көн буе камап тора һәм әлеге сугышта аерым тырышлык күрсәтә. Яһүдиләр үзләренә һәлакәт янавын аңлагач, Пәйгамбәребезгә солых килешүе төзү хакындагы үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Һәм Пәйгамбәребез алар белән солых килешүен төзи, әлеге килешү нигезендә яһүдиләрнең гомерләренә иминлек гарантияләнә, ләкин алар үзләре, бөтен милекләрен калдырып, өсләренә кигән киемнәре белән генә Хәйбәрдән чыгып китәргә тиеш була. Ләкин бераздан ул аларга, ярты уңышны мөселманнарга бирү шарты белән, үзләренең җирләрен эшкәртергә рөхсәт бирә.

### Джә’фәрнең килүе

Пәйгамбәребез ﷺ Хәйбәрдә вакытта Мәдинәгә Әбу Хөрәйрә килә, бу вакытта ул инде Ислам динен кабул иткән була. Шулай ук моңарчы Эфиопиядә яшәп калган мөселманнар да Мәдинәгә күченәләр, алар арасында Пәйгамбәрнең абыйсының улы Джә’фәр бин Әбу Талиб та була. Алар Пәйгамбәребезгә Хәйбәрдә килеп кушылалар. Шулай ук алар белән бергә Әбу Муса Әшгари белән кайбер сәхәбәләр да Мәдинәгә күченеп киләләр.

### Мута янында сугыш

Һиҗри буенча сигезенче елда Мута янында сугыш була. Әлеге сугышка Аллаһның рәсүле Византия императорына Шурахбиль бин Әмра әл-Гассани кешеләре белән бергә җибәргән вәкилнең үтерелүе сәбәп була. Аллаһның рәсүле сәхәбәләр арасыннан өч мең сугышчыдан торган гаскәр җибәрә, гаскәр башы итеп ул үзенең яраткан сәхәбәсе Зәйд бин Харисәне билгели һәм әйтә: “Әгәр Зәйдне һәлак итсәләр, гаскәр белән идарәне үз кулына Джәʻфәр алсын, әгәр Джәʻфәр дә һәлак булса – Габдуллаһ бин Раваха”. Мөселманнарга каршы үзенең гаскәре һәм аңа ярдәм кулы сузган кайбер гарәп кабиләләре белән Ираклий чыга. Мөселманнарга каршы ике йөз мең кеше сугышка күтәрелә. Сугыш Мута дигән җирдә була. Пәйгамбәребез билгеләгән гаскәр башлыкларының өчесе дә һәлак булгач, гаскәрне Халид ибн әл-Вәлид үз кул астына ала. Ул гаскәр белән оста идарә итеп, аны Аллаһның һәм үзләренең дошманнарыннан читкә алып китә.

### Мәккәнең азат ителүе

Шул ук елда корәешләрнең союзнигы булган бәну Бәкр кабиләсе Пәйгамбәрнең союзниклары булган Хуза’а кабиләсенә каршы яу белән чыгалар, әлеге мәкерлекләрендә аларга яшерен рәвештә корәешләр ярдәм итә. Бу хактагы хәбәр Пәйгамбәргә барып ирешкәч, ул Мәккәне яулап алырга карар кыла. Бозылган килешүне кире торгызу максаты белән Мәдинәгә Әбу Суфьян килә. Ул Пәйгамбәр белән сөйләшергә тели, әмма Пәйгамбәребез аны тыңламый. Шуннан соң ул, Пәйгамбәр белән сөйләшүдә ярдәм сорап, Әбу Бәкр, Гомәр, соңыннан Гали янына бара, ләкин алар да аның үтенеч кире кагалар. Пәйгамбәр, үзенең аларга каршы яуга чыгуын корәешләрнең белмәүләрен, “сукыр” булуларын сорап, Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итә. Һәм Аллаһ Тәгалә аның догасына җавап бирә. Пәйгамбәр ун меңлек гаскәр белән Мәккә ягына кузгала. Юлда Пәйгамбәребезгә аның Мәккәдәге абыйсы әл-Габбас бин Габдел-Моталлиб килеп кушыла, ул әле күптән түгел генә Ислам динен кабул иткән була. Пәйгамбәребезнең Мәккәне яулаган вакытта әйткән сүзләреннән берсе шул була: "Кем Әбу Суфьян йортына керсә, шул куркынычсызлыкта булыр. Кем дә кем әл-Харам мәчетендә качып торса, шул кеше куркынычсызлыкта булыр. Кем ишеген бикләп өендә калса, ул куркынычсызлыкта булыр". Мәккәгә кергәндә Пәйгамбәр, каннарын хәләл кылып, бары тик аңа каршы күтәрелеп көрәш башлаганнарга һәм үзенә һәм мөселманнарга зарар китергәннәргә каршы гына сугыша. Пәйгамбәребез Мәккәгә кергәч, ихрамга кермичә генә, Кәгъбә тирәли тәваф кыла. Шуннан соң ул Усман бин Тальханы чакырып китереп, аннан Кәгъбә ачкычларын ала, тышкы яктагы һәм эчтәге потларны җимерә һәм ачкычларны кире Усман бин Тальхага кайтара.

Мәккә яуланганнан соң кешеләр күпләп Исламга керә башлыйлар. Пәйгамбәребез янына килеп, хәтта тулаем кабиләләр дә Ислам динен кабул итәләр.

**Потларны җимерү**

Аллаһ Тәгалә Үзенең пәйгамбренә Мәккәне ачканнан соң, ул үзенең сәхәбәләрен Мәккә тирәсендә булган потларны җимерергә җибәрә. **Әмр бин әл-Әс** Сува’ны җимерергә дип җибәрелә. **Са’д бин Зәйд** Мәнәтне җимерү өчен юллана. **Халид бин әл-Вәлид** әл-‘Узза потын, **Әт-Туфайль** Зөл-Каффәйн потын, ә **Гали** исә Тай исемле потны җимерерү өчен җибәрелә.

**Хунайн янындагы сугыш**

Хавазин кабиләсе халкы Мәккә яулануын ишеткәч, үзләре белән байлыкларын, хатыннарын һәм балаларын алып, Аллаһның рәсүленә каршы яуга күтәреләләр. Аллаһның рәсүле аларга каршы 12 мең сугышчы белән чыга. Кайбер мөселманнарны, Хунайн үзәненә җиткәнче, гаскәрнең шундый санда булуы сокландыра. Ләкин хавазин сугышчылары шулкадәр көтмәгәндә һәм оешкан төстә һөҗүм итәләр ки, күп мөселман сугышчылары, куркудан, Пәйгамбәребез янынннан качышып бетәләр. Аның янәшәсендә мөһаҗирләрдән һәм аның гаилә әгъзаларыннан торган кечкенә генә төркем сугышчылар кала. Аллаһ иман ияләрен ныгыта һәм Пәйгамбәр янәшәсенә җыя. Алар Пәйгамбәр янәшәсендә сугышалар һәм тиздән Аллаһ аларга җиңү бирә. Җиңелгәннән соң хавазин кабиләсе Таиф шәһәренә кача.

Шуннан соң Пәйгамбәребез янына хавазин кабиләсеннән Ислам динен кабул иткән ундүрт кеше килә, алар Пәйгамбәрдән яуда кулга алынган туганнарын азат итүен сорый. Пәйгамбәр кулга алынганнарны азат итә, шулай ук башкалар да әсирләрне азат итәләр.

**Әт-Таифкә яу**

Хавазин кабиләсен тар-мар иткәннән соң, Пәйгамбәр Таиф шәһәренә яу белән чыгарга карар кыла. Пәйгамбәр Таифкә җитә, Таиф ныгытмасын 18 көн буе камап тора, шуннан соң, турыдан-туры сугышка чыгучы булмагач, кире кайта.

**Табукка яу**

Һиҗри буенча тугызынчы елда Табукка яу оештырыла (бу яу бик катлаулы шартларда үтә). Әлеге поход каты эсселек булып, җиләк-җимешләр өлгереп, кешеләрнең агач ышыклыгыннан чыгарга теләмәгән бер вакытында була, шуңа күрә әлеге яуга чыгу кешеләр өчен аеруча авыр була. Пәйгамбәребез әлеге походка чыгарга дигән карарга килгәч, иман ияләрен байлыкларын шул юлда сарыф итәргә чакыра. Госман бин Гаффан иярләре һәм ябулары белән өч йөз дөя һәм шуңа кушып мең динар бирә. Пәйгамбәребез әйтә: "Әлеге көннән соң, ни генә эшләсә дә, Госманга һичбер нәрсә зарар китерә алмас". Калган сәхәбәләр исә үз мөмкинлекләреннән чыгып, байлыкларын ошбу юлда сарыф итәләр.

Күпчелек монафыйклар әлеге походка чыкмыйлар. Шулай ук әлеге яуга, һич сәбәпсез, өч иманлы сәхәбә: Ка’б бин Мәлик, Хиләл бин Умайя һәм Мирара бин әр-Раби’ та чыкмый. Пәйгамбәребез әлеге походтан әйләнеп кайткач, әлеге өч сәхәбә, гафу үтенү нияте белән Пәйгамбәребез янына ашыга, һәм аларга карата “Тәүбә” сүрәсенең 118нче аяте иңә. Аллаһ Тәгалә әлеге өч сәхәбәнең тәүбәләрен, аларның турылыкларын белеп, кабул итә. Һәм әлеге сүрәдә үк Аллаһ монафыйкларны хөкем итә һәм аларның калебләренә бик сала. Әлеге сүрә, монафыйкларны фаш иткәнгә күрә, икенче төрле “Фаш итүче” дип тә атала.

| | |
|---|---|
| **Табукка яу** | Әлеге хәрби походта Пәйгамбәребез янына хөкемдар Айлы Йуханна бин Рауба килә, ул аның белән солых килешүе төзи һәм җизья түли. Джәрбә һәм Азрух вәкилләре дә шул рәвешле эшли һәм җизья түлиләр. Аллаһның рәсүле аларның һәрберсенә дә ышаныч язуы бирә. Пәйгамбәребез шулай ук Думаттан Укайдир белән солых килешүе төзи һәм аның белән җизья түләү хакында килешә. Пәйгамбәребез Табукта ике атна чамасы була һәм шуннан соң, юлда бер генә сугышка да керешмичә, Мәдинәгә кайта.<br>Мәдинәгә кайткач, Аллаh Тәгалә аңарга монафыйклар төзегән зарар мәчетен җимерергә боера. Аллаh Тәгалә Коръәндә әйтә: **“Янә мөселманнар тирәсендә явыз монафыйклар бар ки, алар бу эшләре белән хакны вә нигъмәтләрне инкяр итүләрен арттыру өчен, вә мөселманнарның берлеген бетермәк өчен, вә әүвәлдә Аллаһка һәм Аның расүленә каршы сугышкан кешене көтмәк өчен мөселманнар зарарына мәчет бина кылырлар”** (“әт-Тәүбә” сүрәсе, 107нче аять), һәм Пәйгамбәр әлеге мәчетне җимерә. Әлеге поход Пәйгамбәребез шәхсән үзе катнашкан походларның соңгысы була. |
| **Делегацияләрнең килүе** | Табук явыннан соң сакиф кабиләсе Ислам динен кабул итә. Һиҗри буенча тугызынчы ел “делегацияләр елы” дип тә атала. Пәйгамбәребез янына, Ислам динен кабул итүләрен белдереп, бик күп кабиләләр килә. ‘Атарид бин Хаджиб әт-Тамими җитәкчелегендәге бәну Тамим делегациясе, Зәйд әл-Хайль җитәкчелегендәге Тай кабиләсеннән делегация, әл-Җәруд әл-Габди җитәкчелегендәге Габдел-Кайс кабиләсе делегациясе, бәну Хәнифә делегациясе (алар арасында ялганчы Мөсәйлимә дә була, соңрак ул үзен пәйгамбәр дип игълан итә) шундыйлардан була. |
| **Әбу Бәкрнең хаҗы** | Һиҗри буенча тугызынчы елда Пәйгамбәр Әбу Бәкр җитәкчелегендәге бер төркем мөселманнарны хаҗ кылырга җибәрә, һәм алар барлык тиешле гыйбадәтләрне дә үтиләр. Әбу Бәкрдән соң ук Пәйгамбәр “Тәүбә” сүрәсенең башын халыкларга җиткерү һәм аларга мөшрикләр белән килешүләрнең өзелүен хәбәр итү, бу елдан соң мөшрикләргә җаһилият вакытындагы кебек шәрә килеш хаҗ кылырга һәм Кәгъбә тирәли тәваф кылырга ярамаганлыгы хакында җиткерү өчен Галине җибәрә. |
| **Пәйгамбәрнең хаҗы** | Һиҗри буенча унынчы елда Аллаһның рәсүле хушлашу хаҗын үти. Хаҗ үтәү өчен аңарга төрле кабиләләр һәм шәһәрләрдән кешеләр кушылып, аларның саны йөз меңнән артып китә. Пәйгамбәр ﷺ аларны хаҗ гыйбадәтләренә өйрәтә һәм Гарәфә көнендә аларга вәгазь белән мөрәҗәгать итә, әлеге вәгазендә ул Аллаһ Тәгаләнең ошбу сүзләрен укый: **"Менә бүген динегезне тулысынча ирештердем, бирәсе нигъмәтләремне дә Ислам дине белән бергә биреп бетердем һәм риза булып Ислам динен сезгә ихтыяр кылдым"** (“әл-Маидә” сүрәсе, 3нче аять). Ул Ислам диненең тәгәлләнүе хакында хәбәр бирде һәм мөселманнарга Коръән һәм Сөннәт буенча яшәргә васыять итте, бер-берсенә аларның каннарын, милекләрен һәм намусларын харам итте. Һәм бу аның хушлашу вәгазе иде. |
| **Усаманы җибәрү** | Һиҗри буенча унберенче елның Сәфәр аенда Пәйгамбәребез византиялеләргә каршы сугышу өчен гаскәр әзерли, җитәкчесе итеп Усама бин Зәйдне билгели. Гаскәр әл-Джурф дигән урынга җиткәч, аларга Пәйгамбәребез авырый дигән хәбәр барып ирешә. |

# АНЫҢ ЯУЛАРЫ ХАКЫНДА КЫСКАЧА

**Аның хәрби походлары һәм отрядлары хакында кыскача**

Пәйгамбәрнең барлык хәрби походлары, яулары, хәрби чаралары да һиҗрәттән соң ун ел дәвамында була. Үзе катнашмаган хәрби чараларның саны якынча алтмыш. Ә үзе исән вакытта оештырылган хәрби походлары исә 27. Пәйгамбәребез шуларның тугызында катнаша: Бәдр, Өхед, Хандак (чокыр янындагы сугыш), Курайза, әл-Мусталик, Хәйбәр, Мәккәне, Хунайн һәм Таифны яулау сугышлары. Кайбер походларга карата ошбу аятьләр иңгән:

**Аның хәрби походлары хакында Коръәндә иңгән аятьләр**

**Бәдр янындагы сугыш:** Әлеге сугыш турында “әл-Әнфәл” сүрәсе аятьләре иңә, бу сүрә шулай ук “Бәдр” сүрәсе дип тә атала.

**Өхед сугышы:** “Гыймран” сүрәсенең **"Ий Мухәммәд, Өхед сугышы көнендә өй әһелеңнән чыгып мөэминнәрне сугыш урыннарына урынлаштырган вакытында, Аллаһ синең доганьны ишетүче һәм кәферләрнең эшен белүчедер....",** (“Гыймран” сүрәсе, 121нче аять) аятеннән башлап ахырга кадәр диярлек аятьләр әлеге сугыш хакында.

**Хандак янында сугыш, бәну Курайзага һәм Хәйбәргә яу.** Алар хакында “әл-Әхзәб” сүрәсе аятьләре иңә.

**Бәну ән-Нәдирга яу.** Әлеге яу хакында “әл-Хәшр”сүрәсе аятьләре иңә.

**Худайбийягә һәм Хәйбәргә яу:** Алар хакында “әл-Фәтх” сүрәсе аятьләре иңә. Әлеге сүрәдә **Мәккәне яулау сугышына да** ишарә бар. Әмма турыдан-туры аның хакында “ән-Нәср” сүрәсендә әйтелә.

**Табукка поход**: Әлеге поход хакында “әт-Тәүбә” сүрәсе аятьләре иңә.

Пәйгамбәребез ﷺ бары тик бер сугышта – Өхед сугышында гына яралана. Иман әһелләренә ярдәм итеп, өч сугышта фәрештәләр дә катнаша: Бәдр, Өхед һәм Хунайн сугышлары. Шулай ук чокыр янындагы сугышта да фәрештәләр җиргә төшәләр, алар мөшрикләрне тетрәндерәләр. Пәйгамбәребез мөшрикләрнең йөзләренә ком ата, һәм алар яу кырын калдырып китәләр. Ике сугышта: Бәдр һәм Хунайн сугышларында җиңү яулана. Катапульта бары тик бер генә тапкыр Таифтагы сугышта кулланыла. Чокыр да шулай ук бер генә сугышта кулланыла, ул вакытта мөселманнарга каршы төрле кабиләләр каршы чыга. Чокыр казырга кирәк, дип Сәлмән әл-Фәриси киңәш итә.

# АНЫҢ АВЫРУЫ ҺӘМ ВАФАТЫ

Аның авыруы һәм вафаты

Шуннан соң Аллаһ Тәгалә Үзенең пәйгамбәренә сайлау мөмкинлеген бирә: яки бу дөнья, яки Аллаһ белән очрашу һәм Җәннәт. Ул Аллаһ Тәгалә белән очрашуны һәм Җәннәтне сайлый. Шуннан соң ул каты авырый башлый һәм башка хатыннарыннан авыруы вакытында Гайшә йортында калырга рөхсәт сорый, алар риза булалар. Мәчеткә килеп намаз укый алмый башлагач, ул Әбу Бәкргә җәмәгать намазын җитәкләргә боера. Бу аның үзеннән соң хәлиф булып калырга Әбу Бәкрнең башкаларга караганда лаеклырак икәнлегенә ишарә була. Һиҗри буенча унберенче елның Рабигуль-әүәл аеның 12нче көнендә, мөселманнар мәчеттә иртәнге намазны укыган вакытта, Пәйгамбәребез көтмәгәндә, Гайшә бүлмәсендәге пәрдәне күтәреп, намаз укучыларга карап тора башлый һәм елмаеп куя. Шуннан соң ул аларга намазларын тәгәлләргә тиешлеген белдереп ишарә ясый һәм пәрдәне төшерә.

Һәм иртә белән, кояш югарыга күтәрелгәч, Пәйгамбәребез вафат була.

Пәйгамбәребезнең вафаты мөселманнар өчен моңарчы күрелмәгән зур кайгы иде, һәм алар чиктән тыш хәсрәттә булдылар.

Шуннан соң Пәйгамбәребезне юалар һәм өч ак киемгә төрәләр. Ул вафат булган урынында – иман ияләренең аналары Гайшә бүлмәсендә җирләнә.

Бу Аллаһның әмеренә таянып эшләнә, чөнки пәйгамбәрләр кайда вафат булсалар, шунда җирләнәләр.

Кешеләр һәм җеннәр аның өчен Аллаһтан рәхмәт һәм иминлек сорыйлар. Ул үз бурычын үтәде, үзенең өммәтенә карата эчкерсез мөнәсәбәттә булды һәм Аллаһ ризалыгы өчен иң яхшы сурәттә тырышлык күрсәтте дип, без шәһәдәт бирәбез. Шуңа күрә өммәте өчен Аллаһ аңа, пәйгамбәрләргә хас булганча, иң зур савап-әҗерләр бирсен. Һәм Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка барча мактау!

# ӨЧЕНЧЕ ИМТИХАН

| Сорау | дөрес | хаталы |
|---|---|---|
| • Пәйгамбәр кайчандыр сарык көтүен көтә һәм бу аның аеруча сабыр булуына һәм көчсезләрне кызгануына һәм кайгыртуына сәбәп була. | ☐ | ☐ |
| • Кырык яшь тулгач, аңарга Аллаһтан вәхий иңә башлый. Аллаһ Тәгалә Үзенең вәхийе белән аны җомга көннәрнең берсендә олуглый. | ☐ | ☐ |
| • Корәешләр Алаһның рәсуленә ﷺ тагын да катырак җәфа китерергә тели һәм Әбу Талиб мәгарәсендә аңа һәм аның гаиләсенә камау, чолганыш оештыра. Бу камап тору өч ел дәвам итә. Әлеге камалыш Пәйгамбәребез ﷺ өчен бик авыр сынау була. Ул тәмамланганда аңа 49 яшь була. | ☐ | ☐ |

• Пәйгамбәребез ﷺ Мәккәдә туа: ☐ Фил елында. ☐ Һиҗрәткә кадәр 53 ел кала. ☐ Ике вариант та дөрес.

• Вәхий иңү: ☐ ялгызлыкка мәхәббәт салынудан башлана. ☐ Хәерле төшләрдән башлана. ☐ Ике вариант та дөрес.

• Вәхийнең дәрәҗәләре саны: ☐ Биш. ☐ Алты. ☐ Өч.

• Аның чакыруының дәрәҗәләре: ☐ Ике. ☐ Өч. ☐ Биш.

• Шуннан соң ул төнлә ... Иерусалимдагы әл-Акса мәчетенә күчерелә һәм шуннан ... күкләрдән дә югарырак Аллаһ Тәгалә тарафына күтәрелә. Аллаһ Тәгалә аңа мөрәҗәгать итеп сөйли һәм биш вакыт намазны фарыз итә: ☐ Тәне белән. ☐ Җаны белән. ☐ Тәне вә җаны белән.

• Исламдагы беренче мәчет: ☐ әл-Харам мәчете. ☐ Пәйгамбәр мәчете. ☐ әл-Акса мәчете. ☐ Куба мәчете.

• Кыйбланы үзгәртү: ☐ Мәккәдә вакытта һиҗрәткә кадәр була. ☐ Һиҗри буенча икенче елда була. ☐ Һиҗри буенча өченче елда була.

• Бәдр сугышы Рамазан аенда була: ☐ Һиҗри буенча икенче елда. ☐ Һиҗри буенча өченче елда.

| Аллаһның рәсүленә беренче иман китерүче: | Гали бин Әбу Талиб | Биләл бин Рабәх | Зәйд бин Харисә | Әбу Бәкр |
|---|---|---|---|---|
| Ир-атлардан | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Балалардан | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Азат ителгәннәрдән | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Коллардан | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| Балачакта аны кайгырту: | Әбу Талиб | Габдел-Мотталиб | 8 яшьләр чамасы | Габдуллаһ бин Габдел-Мотталиб | 7 яшь |
|---|---|---|---|---|---|
| Әнисенең вафатыннан соң аны бабасы ... кайгырта | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Аңа ... яшьләр чамасында бабасы да вафат була | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Шуннан соң аны әтисе ягыннан абыйсы ... кайгырта | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Әнисенең карынында вакытта ук аның әтисе ... вафат була | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Әнисе вафат булганда аңа әле ... яшь тә тулмаган була | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

| Аның сугышлары һәм хәрби яулары: | 10 ел | алтмыш | 27 | Шуларның тугызында | Бер сугышта |
|---|---|---|---|---|---|
| Барлык хәрби походлар, яулар, Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң ... дәвамында була | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Аның сугышлары һәм хәрби походлары якынча | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Аның сугышлары | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Пәйгамбәр үзе ... сугышта катнаша | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |
| Ул ... яралана | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ | ☐ |

# КИТАПНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ


| | | |
|---|---|---|
| • Кереш сүз | ......................................... | 3 |
| • Пәйгамбәребезнең шәхси сыйфатлары | ......................................... | 5 |
| • Беренче имтихан | ......................................... | 13 |
| • Пәйгамбәрнең кешеләр өчен кулланмасы | ......................................... | 16 |
| • Икенче имтихан | ......................................... | 21 |
| • Пәйгамбәребезне аерып торучы сыйфатлар | ......................................... | 25 |
| • Пәйгамбәребезнең туганнары һәм хатыннары | ......................................... | 28 |
| • Аның пәйгамбәрлеккә кадәр тормышы | ......................................... | 33 |
| • Вәхий иңә башлау | ......................................... | 35 |
| • Пәйгамбәр тормышының Мәккә чоры | ......................................... | 38 |
| • Пәйгамбәр тормышының Мәдинә чоры | ......................................... | 41 |
| • Аның яулары хакында кыскача | ......................................... | 48 |
| • Аның авыруы һәм вафаты | ......................................... | 49 |
| • Өченче имтихан | ......................................... | 50 |
| • Китапның эчтәлеге | ......................................... | 52 |